Түгәрәк уен

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ

2/ 2024

XIX гасыр чигешләренә хас булган чәчәкле-үсемлекле бизәкләрне хәзерге заман юнәлешләрендәге киемнәрне тегү-кисүдә файдалану татар орнаментын уңайлы кием аша үстерергә мөмкинлек бирә.

МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ
ТАТАРСТАН
ГОСУДАРСТВЕННЫЙ РОССИЙСКИЙ ДОМ НАРОДНОГО ТВОРЧЕСТВА ИМЕНИ В.Д. ПОЛЕНОВА
ГРАНТ
МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТ КУЛЬТ РЕСУРС ЦЕНТР
2024 ГОД СЕМЬИ
КУЛЬТУРА
НАЦИОНАЛЬНЫЕ ПРОЕКТЫ РОССИИ

Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

Казанда –
II Бөтенроссия балалар ФОЛЬКЛОРИАДАСЫ

19-23 июньдә Казанда II Бөтенроссия балалар Фольклориадасы үтте. Россия төбәкләреннән 10 яшьтән 18 яшькә кадәрге 1000нән артык бала килде.

– Алар барысы да милли йолаларны, гореф-гадәтләрне саклаучылар, популярлаштыручылар. Проектта Россия Федерациясенең 80 төбәгеннән балалар фольклор, хореография һәм җыр коллективлары, милли уен кораллары ансамбльләре катнашты. Бу зур чара Татарстанда гына түгел, ә бөтен Россия мәдәни тормышындагы иң күренекле вакыйгаларның берсе булды, – диде Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге директоры Алсу Мифтахова.

Балалар Фольклориадасында катнашучылар өчен махсус масте-класслар оештырылды. Алар «Дуслык әйлән-бәйләне»ндә, костюмлаштырылган йөрештә катнаштылар. Фольклориада чаралары Биектау, Апас, Лаеш, Яшел Үзән районнарында да узды.

Икенче тапкыр оештырылучы Бөтенроссия балалар Фольклориадасы үзенчәлекле проект. Ул Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының финанс ярдәме белән «Халык иҗаты – балаларга» проекты кысаларында гамәлгә ашырыла. Беренчесе аның 2022 елда Чувашстанда Чабаксар шәһәрендә үткән иде.

Әлеге масштаблы иҗади акция Россия Федерациясе халыкларының һәм этник берләшмәләренең мәдәни үзенчәлеген саклауга һәм

мәдәни мирасын популярлаштыруга, үсеп килүче буынны әхлакый-эстетик тәрбияләү бурычларын тормышка ашыруга, илдә балалар һәм яшьләр фольклор хәрәкәтен үстерүгә ярдәм итү максатыннан үткәрелә.

Оештыручылар – В.Д. Поленов исемендәге Россия Дәүләт халык иҗаты йорты, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге, «Разноцветье» иҗади инициативаларны үстерү үзәге.

ЭЧТӘЛЕК

ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТРАДИЦИОН МӘДӘНИЯТЕ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

4 **Татар халкының традицион киемнәрен өйрәнәбез**

6 **«Мәхәллә» иҗат киңлеге» проекты башланды**

8 **«Татарстанның мәдәни башкаласы» бәйге-фестивале старт алды**

10 **Алтынлап чигу курслары**

12 **«Чүлмәк әйләнәсенең кире кайтуы» проекты**

ЗӘВЫКЛЫЛЫК БЕЗДӘН БАШЛАНА

14 Э. Шәйхи
Иҗатымда – үзем

ҺӨНӘРЛЕ ҮЛМӘС…

18 З. Садыйкова
«Эш никадәр катлаулырак – шуның кадәр кызыклырак»

22 З. Мөбәрәкшина
Ямаширмә авылында – остаханә-музей

25 Г. Бахитова
Рәсемнәр белән чигелгән тарих

Түгәрәк уен
№2 (52) / 2024

Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,
моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.
Г. Тукай

16+ Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

Гамәлгә куючылар:
Татарстан Республикасы Мәдәнията министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге

Редколлегия:
Ирада Әюпова
Марсель Бакиров
Тәлгат Галиуллин
Дания Заһидуллина
Марс Тукаев
Фәрит Юсупов

Директор: Алсу Равил кызы Мифтахова
Баш мөхәррир: Рәзинә Әхтәм кызы Исмәгыйлева

Альманахның иҗат төркеме:
Гөлназ Латыйпова
Илнара Гәрәева

Дизайнер һәм биткә салучы:
Диләрә Нәүрузова

Альманах 2020 елның 13 ноябрендә элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79590. Журнал өч айга бер чыга. Бәясе ирекле.

Кәгазь форматы 60×90 ⅛.
Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды: 19.06.2024
Чыгу көне: 26.06.2024
Заказ: 50. Тираж: 1000 экз.

Редакция һәм нәшер итүче:

420021, Казан, Тукай ур., 74 а.
Хатлар язар өчен адрес:
420015, Казан, Пушкин ур., 66/33
Телефон: 293-27-99.
E-mail: tugarakuen@mail.ru

«Фолиант» ҖЧҖндә бастырылды.
Казан, Восстание ур., 100, корп. 6130

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен» альманахына сылтама ясау мәҗбүри.

Тышлыкта: BURO BANU остаханәсе коллекциясеннән.

© «Түгәрәк уен», 2024

ӘДӘБИ МИРАС

28 Л. Мөхәммәтҗанова
Йола җырлары

МИФОЛОГИК МИРАС

33 Г. Гыйльманов
Мифлар каян барлыкка килгән?

ГАИЛӘ ЕЛЫ

37 Э. Галимова
Гаилә йолаларын саклау

ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮРКӘМ ЙОЛАЛАРЫ

40 Л. Җамалиева
«Кушкапка» бәйрәме

42 А. Фазылҗанова
«Яңгыр теләү» йоласы

43 Р. Зарипова
«Печән өмәсе» йоласы

БЕЗГӘ ЯЗАЛАР

46 Р. Гайфуллина
«Мишәрләрем...»

48 Г. Сәлахова
Театр сәнгатен яратучылар

БЕЗНЕҢ КИТАПХАНӘ

50 **Дүртенче томда – тылсымлы әкиятләр**

51 **Укыган бала**

53 **Бер карчыкның улы**

БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...

54 Р. Шәйдуллина
«Яңгыр чакыру» кичәсе

57 **Кикирикүк** *(җыр)*

ӨЙ КҮРКЕ – АШ

58 **«Татарханә» проекты**

60 **Миндальле печенье**

ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ

62 **Бергәләп бизибез!**

Татар халкының традицион киемнәрен өйрәнәбез

Былелның март аенда Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге «Татар халкының традицион киемнәре. Өйрәнү һәм трансляция методлары» дип аталган семинар оештырды. Әлеге уникаль проект әйдәп баручы мәдәният, сәнгать белгечләрен, кием тегү осталарын, дизайнерларны һәм бу темага битараф булмаган башка кешеләрне үзенә туплады.

Семинарда «XXI гасырда авыл җирлекләрендә мәдәниятне программалаштыру. Татар хатын-кызы дөньясы» темасы белән мәдәният фәне кандидаты, «Татар хатын-кызы дөньясы» проектына нигез салучы, «Тамга» шәһәр тикшеренүләр институтын оештыручыларның берсе Энҗе Дусаева чыгыш ясады. Традицион киемнең төп компонентлары, материалы һәм бизәге турында Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр институты Татарстан тарихы, антропологиясе һәм этнографиясе кафедрасы доценты Елена Гущина сөйләде. Сәнгать фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Мәдәният советы әгъзасы, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының фәнни хезмәткәре Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова «Традицион кием – халык сәнгатенең бер төре» һәм «Хәзерге заман татар киеменең үсеш тенденцияләре» темаларына доклад укыды. Н. Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесы укытучысы Регина Шамееваның традицион киемне конструкцияләүнең төп кагыйдәләре турында һәм училище директоры Ольга Гыйльметдинованың «Татар традицион сәнгатендә төс» темасына багышланган чыгышлары кызыксыну уятты.

Дизайнер, BURO BANU локаль брендына нигез салучы Элара Шәйхи чыгышында татар халкының тарихы һәм традициясе аша яңа кием уйлап табудагы тәҗрибәсе белән уртаклашты, коллекциясенең бер өлешен дә күрсәтте. Теләгән кешеләргә аның дизайнер осталыгы белән якыннанрак танышырга мөмкин булды.

Самара өлкәсенең «Заман» балалар фольклор коллективы җитәкчесе Вәсимә Фәрдиева коллективның репертуары һәм киемнәр комплексы өстендә эшләү тәҗрибәсе белән уртаклашты. Ә коллективның чыгышын көчле алкышлар белән каршы алдылар. Фольклор ансамбльнең иң кечкенә катнашучылары тамашачылар күңеленә аеруча хуш килде.

Семинарның бер өлеше «Казан Кремле» Музей-тыюлыгының «Присутственные места» тарихи бинасында дәвам итте. Бирелә ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының фәнни хезмәткәре Динә Гатина-Шәфыйкова XVI-XIX гасыр рәсемнәрендәге татар образларын күрсәтте. Семинарда катнашучылар «Казан Идел буе: халык мәдәнияте образлары» семинарында һәм күргәзмәсендә булдылар. Сәнгать белеме докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге мөдире Рауза Солтанова «Татар киеме. Россия этнография музее» альбом-каталогына презентация үткәрде.

«Мәхәллә» иҗат киңлеге» проекты башланды

2024 елның 1 апрелендә Татарстан Республикасының Арча, Апас, Чүпрәле, Кукмара, Мөслим, Балык Бистәсе, Саба муниципаль районнары авыл Мәдәният йортлары базасында «Мәхәллә» иҗат киңлеге» проекты башланып китте.

«Мәхәллә» иҗат киңлеге – уникаль арт-кластер, анда сәнгатьне бәяли белүчеләр һәм яратучыларны тупларга ниятлиләр. Бу – сынлы сәнгать һәм рәсем дәресләре, арт-коворкинг, тукучылар, чигүчеләр, киез басучылар, агачка уеп рәсем ясаучыларның берләшмәләре һәм үзләре кызыксынган юнәлешләр буенча башка клуб берләшмәләре булырга мөмкин.

Проектның максаты – «Мәхәллә» иҗат киңлеге аша этномәдәни күптөрлелекне, халык иҗатын, матди булмаган мәдәни мирасны, традицион гаилә-рухи кыйммәтләрне саклау һәм популярлаштыруга ярдәм итә торган мәдәни ял мәйданчыкларын үстерү.

● Кукмара районы Туембаш авылы Мәдәният йортында «Йонлы тарихлар» дигән иҗат киңлеге эшли башлады. Ул бирердә фелтинг – энәләр, фильцевкалау машинасы һәм сабын суы ярдәмендә йон басу техникасын үзләштерүне күздә тота.

Татарлар тормышында киез итек басу элек-электән булган. Бүген бу – Кукмара районының горурлыгы, бренды. Проектның идеясе әлеге һөнәр күнекмәләрен авылда яшәүче яшь буынга тапшыруны гына түгел, итек басуның заманча төрләре белән шөгыльләнергә теләүчеләргә өйрәнү мөмкинлеген дә үз эченә ала. Проектны гамәлгә ашырганда авыл халкының йон басудагы осталыклары нигез итеп алыначак – Туембаш һәрвакыт үзенең киез ителәре белән дан казанып яши. Киләчәктә әлеге проект кысаларында балалар һәм үсмерләр өчен дә мастер-класслар үткәрергә ниятлиләр.

● Саба районы Лесхоз авылы Мәдәният йортында «Мәхәллә» иҗат киңлеге кысаларында «Саба бизәкләре» иҗат проекты эшли башлады. Июнь аенда агач кашыкларны бизәү буенча чираттагы мастер-класс булды. Бу проект анда катнашучыларга әлеге бабаларыбыз һөнәре серләренә төшенергә, кулларның хәрәкәт активлыгын һәм сизгерлеген үстерергә, төгәллеккә һәм күз үлчәменә өйрәнергә мөмкинлек бирә.

● Арча районы Ташкичү авылы Мәдәният йорты каршында да «ТатАРЧА бизәкләр» иҗат остаханәсе эшли башлады. Беренче очрашуга килгән чигүче осталар һәм чигү техникасын яхшы белүче «Өммегөлсем» фольклор ансамбленә йөрүчеләр, татар милли чигешләр буенча үзләренең осталыкларын яшь буынга – мәктәп укучыларына тапшырырга әзер булуларын белдерделәр. Яшь кул осталары яңа һөнәр үзләштерергә бик теләп алынды. Әлеге чарада 6 өлкән кеше һәм 12 кыз бала катнашты.

● Балык Бистәсенең Күгәрчен авылы Мәдәният йорты каршында «Бистә шәле» проекты башланып китте. Мәгълүм булганча, Балык Бистәсе мамык шәл бәйләүче осталары белән данлыклы. Элек-электән бу һөнәр буыннан-буынга тапшырылып килә. «Мәхәллә» проекты ачылышында Күгәрчен авылының бәйләү осталары, мәктәп укучылары һәм авыл кешеләре катнашты. Алар бу һөнәрнең килеп чыгу тарихы белән таныштылар. Аннан соң профессиональ шәл бәйләүче мастер-класс күрсәтте.

«Татарстанның мәдәни башкаласы» бәйге-фестивале старт алды

Бу елның 22 апрелендә Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында «Татарстанның мәдәни башкаласы» бәйге-фестивале башланып китте. Муниципаль берәмлекләр арасында узучы бәйгегә узган елны Гран-при яулаган Арча районы старт бирде. Алар башкала кунакларына «Нәсел җебем синдә, Арчам!» дип исемләнгән концерт-тамаша тәкъдим иттеләр. Мәсәлән, «Хезмәт, тәрбиянең нигезе – гаиләдә» дип исемләнгән остаханәләрдә һәркем чыбыркы үрә, каз каурыеннан май канаты ясый, корт төя, чалгы таптый алды. «Шәҗәрә-гаилә тарихы» күргәзмәсендә районның күренекле шәхесләренең гаилә архивы, нәсел шәҗәрәсе белән таныштылар. Чыпта сугу, зәркәнчелек, алтын җеп белән чигү, читек чигү, агачны бизәкләп эшкәртү һәм чүлмәкчелек, керамика сәнгате, киез басу, келәм туку, тимер эшкәртү буенча да осталык дәресләре үткәрелде.

Башкала кунаклары Арча ягында бүгенге көнгә кадәр сакланып калган «Кыз алу» йоласында, кияү егетен сынауда катнаштылар.

«Быел «Татарстанның мәдәни башкаласы» бәйге-фестивале Гаилә елына багышлана. Җиңүче район федераль яки төбәк мәдәни проектларының берсен гамәлгә ашыру урыны булачак. Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән бәйгенең приз фонды артты, бәйгедә җиңүче төбәкне 4 миллион сумлык сертификат көтә», – диде фестиваль ачылышында Татарстан мәдәният министрының беренче урынбасары Юлия Әдһәмова.

Зөлфәт Сибагатуллин фоторәсемнәре

Алтынлап чигү курслары

2024 елның 25-26 апрелендә һәм 6 майда Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге «Казанның чигүле бизәкләр мәктәбе» автономияле коммерцияләнмәгән оешмасы белән бергә алтын чигүле бизәкләр буенча курслар оештырды. Белем арттыруга юнәлтелгән әлеге программада катнашучылар арасында профессиональ чигүчеләр генә түгел, алтынлап тегүне җентекләбрәк өйрәнергә теләүчеләр дә бар иде.

Семинарда катнашучылар сәнгать фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Мәдәният советы әгъзасы Гүзәл Вәлиева-Сөләйманованың «Чигү сәнгате: башкару техникасы һәм образлар» һәм «Хатын-кыз киеме ансамблендә калфак» дигән лекцияләрен тыңладылар.

Курсларда татар хатын-кызлары киеменең иң билгеле атрибуты – калфак ясау буенча мастер-класс үткәрелде. Аны 30 ел стажы булган алтынлап чигү остасы-реставраторы, алтынлап тегү остаханәсе җитәкчесе һәм Казанның бизәкләп чигү мәктәбенә нигез салган Аглая Липина уздырды. Шулай ук ул иң киң таралган калфак төрләре һәм аларның исемнәре белән җентекләп таныштырды, аны кисү һәм ясауның үзенчәлекләре турында сөйләде.

Аглая Липина Казанда туган, Торжок сәнгатьле чигү мәктәбен тәмамлаган, Санкт-Петербургтагы Пушкин реставрацияләү остаханәләрендә стажировка узган. 2000 нче еллар башында ТР Халык һөнәрләре үзәге каршында ул төзегән алтынлап тегү остаханәсе ТР Президенты аппараты, Казан мэриясе, Казан епархиясе, «Татнефть», «Татспиртпром» структуралары заказы буенча уннарча авторлык проектын гамәлгә ашырды. Казаннан тыш, Аглая Липина һәм аның укучыларының эшләре Мәскәү, Екатеринбург, Чиләбе, Париж күргәзмәләрендә куелды. Аглая Липина остаханәсе әсәрләре Татарстан Милли музеенда, «Туран» Фонды музеенда күрсәтелде, алар күп кенә башка дәүләт һәм шәхси коллекцияләрдә саклана.

Курслардагы эш барышында анда катнашучылар Ә. Мәҗитов музее мөдире, рәссам, сәнгать фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе

Луиза Фәсхетдинованың «Традицион калфак: төп компонентлары, материалы, бизәге» дигән темага лекциясен тыңладылар. Семинар барышында шулай ук республикабызның чигелгән картасы белән таныша алдылар. Курста катнашучыларның кайберләре районнарының картасын үзләре чиккән булып чыкты. Алар тәҗрибәләре белән уртаклаштылар, «Татарстанның чигелгән картасы» проекты барышы турында җентекләбрәк сөйләделәр.

Курста катнашучыларга өй эше дә бирелде: бер атна эчендә үз калфакларын чигәргә һәм эшләп бетерергә. Онлайн-режимда аларга мастер-педагог Аглая Липина ярдәм итеп торды. Чигүчеләр куелган бурычны бик яхшы башкардылар. Һәр катнашучы алтынлап тегү нигезләрен үзләштерүләрен генә түгел, үз эшләнмәләрен бизәкләп, бик күп чигеш төрләрен белүләрен дә күрсәттеләр. Кайберәүләр хәтта ике калфак ясарга да өлгерде.

6 майда, курсларның соңгы көнендә, калфаклар ясалып беткәннән соң, эш нәтиҗәләре программа экспертлары – сәнгать фәннәре докторы Гүзәл Фуад кызы Вәлиева-Сөләйманова һәм өч көн дәвамында курсларның практик өлешен үткәрүче Аглая Липина хөкеменә куелды. Һәр катнашучының эшенә индивидуаль бәя бирелде, кимчелекләр күрсәтелде һәм аларны төзәтү буенча киңәшләр әйтелде.

«Өч көн эчендә без шулкадәр туганлашып беттек, аерылышу хәтта ямансу да. Курсларны оештыручыларга һәм безнең экспертларга, осталарга чигү сәнгатендә зур белемнәргә ия булулары, укытуда индивидуаль якын килә белүләре, традицион технологияләрне саклап, үз калфагыбызны ясау мөмкинлеге бирелү өчен зур рәхмәтебезне белдерәбез», – диде чигүчеләр.

«Чүлмәк әйләнәсенең кире кайтуы» проекты

Бүгенге көндә Татарстан Республикасында «Чүлмәк әйләнәсенең кире кайтуы» / «Возвращение гончарного круга» проекты гамәлгә ашырыла. Мәдәни инициативаларның Президент фонды тарафыннан хупланган әлеге проект өстендә «5 стихия» керамика һәм һөнәрләр үзәге» эшли.

«5 стихия» автономияле коммерцияләнмәгән оешма бу проект кысаларында 1912-1927 еллардагы чүлмәк эшләнмәләренең югалган үрнәкләрен кабат торгыза, алар күргәзмәләрдә Татарстан Республикасын төрле дәрәҗәдә күрсәтә алачак. Проект җитәкчесе, рәссам-керамист, ТР сәнгать һөнәрчелеге остасы Наталья Пилюгина әйтүенчә, проект Татарстандагы керамика һөнәрен үстерүдә зур әһәмияткә ия. «Чүлмәк әйләнәсенең кире кайтуы» керамик эшләнмәләр җитештерү тарихы буенча уку-укыту базасы булачак, һәм бу анда катнашучыларга иҗади профессия күнекмәләре үзләштерү һәм сәнгать аша социальләшү мөмкинлеге бирәчәк. «Чүлмәк әйләнәсенең кире кайтуы» проекты кысаларында, Питрәч районының Туган якны өйрәнү музее белән бергә, балалар өчен чүлмәк ясау осталыгы, әвәләү, керамик эшләнмәләргә бизәк төшерү, халык сәнгать һөнәрләре һәм орнаментлар тарихы турында лекцияләр уку буенча иҗади белем бирү сменасы, шулай ук сәнгатькә кызыксыну формалаштыру һәм культура дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән күргәзмә-конкурс, иҗади смена оештырылачак.

Бу юнәлештәге эшчәнлек бик актив алып барыла. Мәсәлән, Наталья Пилюгина Н.И. Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесында уңышлы эшләп килә торган Креатив индустрияләр мәктәбе студентлары өчен мастер-класслар үткәрә. Шушы көннәрдә керамика буенча мастер-класска

әлеге мәктәпнең 20 укучысы җыелды. Алар балчык белән эш итәргә, үзләре нәрсә дә булса уйлап чыгарырга бик теләп өйрәнделәр. Бер сәгать эчендә укучыларның һәркайсы җансыз балчык кисәген әвәләп, үз мәчесен ясады. Кемнеңдер ул бик җитди, тәкәббер, ә кемнеңдер шаян, көлкеле булып чыкты. Матур, нәзакатле песиләр дә бар иде. Ә иң мөһиме, бу дәрес укучыларда балчык, керамика эшенә кызыксыну уята алды.

«5 стихия» керамика һәм һөнәрләр үзәге» автономияле коммерцияләнмәгән оешма шулай ук керамика предметларын, Казан губернасының Питрәч авылында сәнгать һөнәре укыту остаханәсе төзелүгә (1905-1923 еллар) караган документларны өйрәнү белән дә шөгыльләнә. Наталья Пилюгина әйтүенчә, әлеге укыту остаханәсе белгечләрен Штиглиц Академиясендә хәзерләгәннәр. Бу остаханә ТАССРда гына түгел, бөтен Идел буе һәм Идел аръягында бердәнбер кустарь һөнәрчелекне үстерү үзәге булган. 1927 елда ул илнең укыту-күрсәтмә остаханәләре челтәренә кертелгән.

Алга таба проект барышында, «Чүлмәк әйләнәсенең кире кайтуы» грантын башкару кысаларында, Питрәч керамикасы эшләнмәләренең электрон каталогын һәм Татарстан керамикасының фәнни басма каталогын төзү планлаштырыла. Бүгенге көндә шулай ук Татарстан Республикасында сәнгать керамикасы тарихы турында документаль фәнни-популяр фильм төзү өстендә эш алып барыла.

Диана Сәмигуллина фоторәсемнәре

Яңалыклардагы фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

ИҖАТЫМДА – ҮЗЕМ

BURO BANU
est.2017

МИН, ЭЛАРА ШӘЙХИ – BURO BANU БРЕНДЫНА НИГЕЗ САЛУЧЫ ҺӘМ АНЫҢ ДИЗАЙНЕРЫ. БҮГЕН МИН ҮЗ ДӨНЬЯМНЫ АЧЫП САЛЫП, СЕЗНЕ ДӘ УЙ-МАКСАТЛАРЫМ ҺӘМ ИДЕЯЛӘРЕМ БЕЛӘН РУХЛАНДЫРЫРГА ТЕЛИМ.

Үзенчәлекле көнчыгыш колоритын үзендә саклаган тарихи урында иҗади фикерләр туа. Модерн стилендәге архитектура, алсу төстәге ике катлы агач йорт, тәрәз төпләрендәге чүлмәкле яран гөлләре гаҗәеп бер атмосфера тудыра.

Брендыбызның исеме 19нчы гасыр азагы – 20нче гасыр башында яңа Казан модасын уйлап табучы Бибимәрьямбану Аппакова образы белән бәйле. Европа белеменә һәм югары сәүдәгәр нәселе статусына ия булган Аппакова татар милли киеменә төрле мода юнәлешләре алып килә, һәм алар шунда ук киң кулланылыш таба. Коллекциябезнең нигезендә нәкъ менә әлеге принцип ята.

Үз алдыма тарихи үткәнне һәм хәзерге заманны берләштерү бурычын куеп, үткән белән бүгенге арасындагы чикнең зур булмавын аңлаган хәлдә, бу өлкәдә яңа юллар эзлим.

МИН КӨН САЕН ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ МӘДӘНИ КОДЫН ЭЗЛӘҮ БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНӘМ, ТРАДИЦИОН КИЕМ ҺӘМ АНЫ КИСҮ-ТЕГҮ ЭВОЛЮЦИЯСЕ ТАРИХЫН ӨЙРӘНӘМ, МИЛЛИ БИЗӘКЛӘР ҺӘМ АНЫҢ МӘГЪНӘСЕ ӨСТЕНДӘ ЭШЛИМ, КУЛДАН ТЕГҮ ҺӘМ МЕХАНИК ХЕЗМӘТНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ МӨМКИНЛЕКЛӘРЕН ХӘЛ ИТӘМ.

ТИҢЕ БУЛМАГАН УНИКАЛЬ ЭШЛӘНМӘ ҖИТЕШТЕРГӘНДӘ ШАКТЫЙ ГЫНА СОРАУЛАРГА ЮЛЫГАСЫҢ. ФОРУМНАРДА, ФЕСТИВАЛЬЛӘРДӘ БАШКАЛАР БЕЛӘН АРАЛАШКАНДА ПРОБЛЕМАЛАРНЫҢ ОХШАШ БУЛУЫНА ТӨШЕНӘСЕҢ. ТӨП МӘСЬӘЛӘНЕҢ ШУНДА БУЛУЫН АҢЛЫЙСЫҢ: ИДЕЯНЕ ФОРМАЛАШТЫРУ, АНЫ АВТОР ФИЛОСОФИЯСЕ һӘМ ПРОДУКТНЫҢ КЫЙММӘТЕ АША ГАМӘЛГӘ АШЫРУ, ҮЗ ХАЛКЫҢНЫҢ ТАРИХЫН һӘМ ТРАДИЦИЯЛӘРЕН ТИРӘНТЕН БЕЛҮ НИГЕЗЕНДӘ ЯҢА ПРОДУКТ ҖИТЕШТЕРҮ.

Продуктка салынган мәгънәләрне күрсәтеп бирү, мөһим мәсьәләләр турында сөйләшү, тәҗрибәң һәм белемнәрең белән уртаклаша алу мөмкинлеге – ышаныч казануның мактаулы миссиясе. Мондый мөмкинлек бирелү өчен мин һәрвакыт рәхмәтле.

Традицияләр миңа гасырлар аша узып, кабат җан өрдерелгән гаять әһәмиятле мәңгелекне табарга ярдәм итә.

ЯҢА ТРЕНД ТУДЫРГАНДА МИН, БОРЫНГЫ БИЗӘКЛӘРНЕ САК КЫНА ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН ЮНӘЛЕШЛӘРЕНДӘ КУЛЛАНЫП, АЛАРНЫ САКЛАП КАЛАМ.

ИЗҮ – ТАТАР ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ КИЕМЕ КОМПЛЕКСЫНЫҢ АЕРЫЛГЫСЫЗ ӨЛЕШЕ, УЛ ЭЛЕК-ЭЛЕКТӘН ДЕКОРАТИВ ҺӘМ ФУНКЦИОНАЛЬ ӘҺӘМИЯТКӘ ИЯ БУЛГАН. ОЗАК ЕЛЛАР ОНЫТЫЛЫП ТОРГАННАН СОҢ, ИЗҮ КАЗАН ШӘҺӘРЕ ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ КИЕМНӘРЕНЕҢ ТӨП ӨЛЕШЕ БУЛЫП КИТТЕ.

BURO BANU ЛОКАЛЬ БРЕНДЫ ПОПУЛЯР БУЛА БАРА.

Орнаментларны өйрәнгәндә XIX гасыр чигешләренә хас булган чәчәкле-үсемлекле бизәкләрнең челтәрлелегенә һәм катлаулылыгына гашыйк булам. Ә аларны хәзерге заман юнәлешләрендәге киемнәрне тегү-кисүдә файдалану (бездә болар – чалбар-палаццо, күлмәк-накидка, биниту) татар орнаментын уңайлы кием аша үстерергә мөмкинлек бирә. Коллекциягә бил тирәсендә салына торган зур кесәләр өстәү камзулның түбән өлеше (күп катламлылык идеясе) булып күренә. Яңа коллекция шулай туа.

МИНЕМ ӨЧЕН АТА-БАБАЛАРЫБЫЗНЫҢ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТ ИТҮ БИК МӨҺИМ, ҺӘМ БУ ИҖАТЫМНЫҢ ТӨП НИГЕЗЕ БУЛЫП ТОРА.

Кием үрнәген кискәндә борынгылык һәм антиквар элементлар – тасмалар, сәйләннәр, материаллар кертү, борынгы заман китап битләреннән сикереп төшкәндәй, уникаль образлар хасил итә. «Яшәү стиле – мәдәни код» фестивале Татарстан дизайнерлары өчен гаҗәеп мөмкинлекләр тудыра. Аңа гаять рәхмәтле булып, без ел саен Казан халкы һәм аның кунакларына авторлык коллекцияләребезне күрсәтәбез, тамашачыларны төрле вакыт аралыгында яшәгән татар хатын-кызларының милли дөньясы белән таныштырабыз.

ЯҢАЛЫК ТУДЫРГАНДА ИЛҺАМЛАНДЫРУЧЫ ФАКТОР БУЛЫП НӘРСӘ ТОРА? БУ – ШАУ-ШУЛЫ ШӘҺӘР ДӘ, ТЫНЛЫК ТА, ҺӘМ ЯХШЫ КЕШЕ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ КОРУ ДА. БОЛАР ҺӘММӘСЕ ДӘ МИНЕМ ӨЧЕН БИК МӨҺИМ. ҺӘМ БУ – МИНЕМ ЯРАТКАН ШӘҺӘРЕМ.

Планетадагы һәрбер кешенең гардеробында капюшонлы трикотаж кием (худи) бар, аны һәркем сатып ала. Әмма без тиз сату принцибы буенча эш итмибез. Халыкка һәм туристларга киемнәребезне туган шәһәребездәге объектлар белән тәңгәлләштерүне күздә тотабыз. Бүген алар республикабызда туып, аннан читтә гомер итүчеләр өчен дә, ватаннарына гашыйк булган, аның белән горурланып яшәүчеләр өчен дә менә дигән бүләк булып тора.

Без үз эшләнмәләребезне танылган кешеләр өстендә дә, гади клиентларыбызда да күрәбез. Аларны тудырганда салынган хезмәтнең сатып алучылар өчен дә әһәмиятле булуын аңлау күңелгә рәхәтлек бирә.

БЕЗ ӘЛЕ ҮЗ ЮЛЫБЫЗНЫ БАШЛЫЙБЫЗ ГЫНА.

МИНЕМ ИДЕЯЛӘРЕМ КҮП ҺӘМ АЛАРНЫҢ ҺӘРКАЙСЫ БИЛГЕЛЕ БЕР ВАКЫТТА ТОРМЫШКА АШЫРЫЛА.

Минем өчен әйләнә-тирәдәгеләремне татар мәдәнияте, гореф-гадәтләре белән таныштыру, белемнәрем һәм тәҗрибәм белән уртаклашу, өйрәнгәннәремне дискуссияләр һәм чыгышлар аша тапшыру бик мөһим.

Традицияләр миңа гасырлар аша узып, бүген кабат җан өрдерелгән гаять әһәмиятле мәңгелекне табарга ярдәм итәләр. Үткән белән киләчәк, иске белән яңа арасындагы чик һич тә зур түгел.

Мин яңа трендлар тудырам, һәм алар милли моданың бер өлеше булып китәләр.

Аның нинди булачагы бездән тора.

ВАКЫТ ЕЛЪЯЗМАСЫНА БЕЗ ҮЗ ТАРИХЫБЫЗНЫ ЯЗЫП КАЛДЫРАБЫЗ.

Фоторәсемнәр BURO BANU остаханәсенең шәхси архивыннан

«Эш никадәр катлаулырак – ШУНЫҢ КАДӘР КЫЗЫКЛЫРАК»

Зөһрә САДЫЙКОВА,
«Ватаным Татарстан» газетасы хәбәрчесе



НИНДИ ДӘ БУЛСА ЯКЛАРГА СӘФӘР ЧЫГАР АЛДЫННАН, ЖУРНАЛИСТ ГАДӘТТӘ ШУЛ РАЙОННЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕН ӨЙРӘНӘ, МАТУР, ЛАЕКЛЫ КЕШЕЛӘРЕН БАРЛЫЙ. ӘЛКИ РАЙОНЫНА КОМАНДИРОВКАГА БАРЫР АЛДЫННАН ДА ТАНЫШЫБЫЗДАН СОРАШТЫК. «БЕЗНЕҢ ИЛЬЯС ИНДЕ! ШУШЫНДА КАДӘР КИЛГӘЧ, АНЫ КҮРМИ КИТМӘССЕЗ», – ДИДЕ. ӘЛКИДӘ ЯШӘҮЧЕ АЛТЫН КУЛЛЫ, САВЫТ-САБА, ВАЗА, АШХАНӘ ӨЧЕН КИРӘК-ЯРАКЛАР, ЭСКӘМИЯ, УРЫНДЫКЛАР, ИШЕКЛӘР, ШАХМАТ ТАКТАЛАРЫ ҺӘМ СЫННАРЫ КЕБЕК ӘЙБЕРЛӘР ЯСАУЧЫ ИЛЬЯС ИДИЯТУЛЛИН БЕЛӘН БЕЗ ӘНӘ ШУЛАЙ ТАНЫШТЫК.

«Мәктәпкә барганчы ук эт оясы ясый идем»

– Мин – Төгәлбай авылы егете, – дип башлады ул сүзен. – Үземне белә башлаганнан бирле агач тирәсендә кайнашам. 4 яшемдә үк тактадан ясалган үземнең верстагым бар иде. Әнинең кәнфиткә дип биргән акчасына нинди дә булса эш коралы алу – минем өчен гадәти күренеш булды. Мәктәпкә барганчы ук эт оялары, уенчыклар ясый идем. Әтинең кирәкле такталарын «эшкә җиккән» өчен дә шактый эләгә иде үземә. Андый чакларда әни әтигә каршы төшеп: «Ачуланма баланы. Әтигә охшаган ул», – дия иде. Сөйләүләре буенча, миңа осталык бабамнан күчкән. Кызганыч, үземә аны күрергә насыйп булмады. Сугыштан яраланып кайтып, 1946 елда мәрхүм булган. Заманында ул Санкт-Петербургта император Николай IIгә хезмәт иткән, итальян һәм немец осталарын саклаган. Күрәсең, шул вакытта аларны күзәткәндер, ә бәлки, ярдәм дә иткәләгәндер. Хезмәттән кайткач, үзе дә өстәл-урындыклар, чүлмәкләр ясаган, дип еш искә алалар иде аны.

Соңрак Ильяс абый умарта оялары ясый башлый. Әлкигә күченгәч, остаханә булдырып, ишекләр эшләүгә тотына.

– Ул вакытларда кибетләрдә ишекләр юк иде. Шуңа күрә минекен чират торып алалар. Махсус исәпләгәнем булмады, ләкин меңгә якын ишек ясалгандыр. Аларны сәүдә нокталарында да табарга мөмкин була башлагач, урындыклар эшләүгә күчтем. Аларның саны тагын да күбрәк. Мин ясаган урындыклар Татарстанның бөтен районында бар.

Ильяс Идиятуллин әйтүенчә, эшләгән эшләре арасында иң кыйммәтлесе дә – урындыклар. Соңгы тапкыр ясаганнарын 6шар

мең сумга саткан. Тик соңгы 1–1,5 елда ул кул хезмәтеннән станок белән эшләүгә күчкән.

– Соңгы елларда ярминкәләр мине үзенә тарта. Савыт-саба, кухня кирәк-яраклары ясап, эшләнмәләремне шунда сатам. Татарстан зур, мондый ысул белән ясаучылар тагын бардыр, әмма минем әлегә очратканым булмады. Гәрчә, бик күп ярминкәләрдә булырга туры килсә дә. Кеше эшләгәненең әҗерен дә күрергә тиеш, шуңа сатам. Шулай да күңелгә иң рәхәте – үзем кебекләр белән танышу, аралашу. Нәрсәгәдер өйрәнәсең, нәрсәгәдер өйрәтәсең, – ди ул.

Ильяс абый ясый торган савыт-сабаларның үзенчәлеге шунда: ул аларны агач кисәкләреннән эшли. Аның өчен имән, каен, нарат, карама, юкә һәм зирек агачларын файдалана. Беренче карашка бизәкләр төшерелгән кебек тоелса да, чынлыкта барысы да – табигать бүләге, аның матурлыгы. Төрле агач кисәкләреннән күз явын алырдай матурлык пәйда була. Мәсәлән, бер вазаны эшләгәндә җиде төрле агач кулланырга мөмкин.

– Караңгырак төс алыр өчен имәнне аммиак парында каралтып алам. Ике тәүлек эчендә агачның эче генә түгел, тышы да карала, – ди оста.

Якын дустым «Ютуб»

«Эшләремнең дәвамлы булуын телим». Монысы да оста куллы Ильяс Идиятуллин сүзләре. Үзе ике кыз үстергән әти булгач, бар белемен Әлкиненең балалар иҗат үзәгендә шөгыльләнүче малайларга тапшыра: елына 40лап баланы укытып чыгара. Аны алга таба укучыларының шул юнәлеш буенча китүләре тагын да сөендерә.

– Тактаны миннән дә остарак кисүчеләр бар, – ди горурланып остазлары. – Минем күзләр бик үк яхшы күреп бетерми хәзер, ә малайлар булдыра! Дөрес, баштагы өч айда үземә дә, аларга да шактый тырышырга туры килә. Белгәнемне башкалар белән бик теләп уртаклашам, чөнки савыт-сабаны теләгән һәр кешегә барыбер үзем генә ясап бетерә алмыйм. Ә мин аларның күпчелек йортта булуын телим. Казан кибетләрендә агачтан ясалган шундый савыт-сабалар ким дигәндә 1200 сум тора. Ә мин

400–500 сумга сатам. Халык сөенә-сөенә ала. Аларга карап мин куанам. Өлкән яшьтәге апаларга шактый арзан бәядән бирәм. Бушка биреп җибәргән вакытлар да шактый була. Ярминкәдәге башка сатучылар аңламый, әлбәттә, мине. «Ник алай эшлисең?» – дип шаккаталар. Ләкин мин яхшылыкның яхшылык булып әйләнеп кайтасына ышанам. Бүген булмаса, иртәгә барыбер кайта ул. Кайтмаса да, күңелдә рәхәтлеге кала. Ярминкәдән кайткач, кемнедер сөендерә алуыма ике көн куанып йөрим. Күп вакыт шул апалардан соң бер абзый килә дә 15 мең сумлык товарымны сатып алып китә. «Яхшылык озак көттермәде», – дип сөенәм андый чакларда.

Алтын куллы останың эшләнмәләрен чит илләрдә яшәүчеләр дә яратып ала икән. Америка, Германия, Казахстан, Перу һәм башка илләрдән бүләккә дип заказ бирүчеләр дә шактый, ди. Мәсәлән, күптән түгел Франциядән заказ белән сандык ясаттырып алганнар. Агач остасы әйтүенчә, шахмат такталарына һәм сыннарга исә күбрәк җитәкчеләр заказ бирә.

– Минем якын дустым бар. «Ютуб» дип атала. Яңа ысулларны шуннан өйрәнәм. Агач кисәкләреннән ясау ысулы исә катлаулылыгы белән җәлеп итте. Гомумән, эше никадәрле авыррак, эшләнмәләрне шуның кадәр теләбрәк ясыйсы килә. Кызыксыну, азарт барлыкка килә. Кызганыч, яшьрәк чакта укыйсым калган минем. Белемем булса, күбрәк уңышка ирешкән булыр идем. Үзлектән өйрәнгәнлектән, агачның җелегенә 40 яшьтә генә үттем. Аның бар нечкәлекләрен, телен өйрәндем. Мәсәлән, агачның төбен тукмакка кулланырга ярый, ләкин ул уклауга бармый. Аңа нарат та ярамый: сумаласы чыга. Нараттан ясалган эшләнмәләрне лак белән дә буяп булмый, шул ук сумаласы этеп чыгара. Чыдамлы булмый. Ә кешеләргә озакка җитә торган сыйфатлы эшләнмәләр эшлисе килә. Шунысы бар: минем савытлар ут һәм су яратмый. Аларны коры ризыклар өчен генә файдаланырга кирәк, – ди Ильяс әфәнде.

Ильяс абый савыт-сабаларны киндер мае, балавыз белән дә буйый. Бу эшләрдә төп ярдәмчесе – хатыны Әлфия.

– Мин ясыйм, ул буйый. Шахматларны шомарту, савытларны буяу – барысы да аның

өстендә. Соңгы вакытларда сатарга да аны ала башладым. Башта оялып торса да, соңыннан остарып китте, – ди гаилә башлыгы.

Оста куллы танышыбыз сүзләре буенча, язын, җәен ярминкәләрдә сата торган савыт-саба, кухня өчен кирәк-яракларны ул кыш буе ясый. Мәсәлән, бер савытны ясау бер атнага кадәр сузылырга мөмкин икән. Вазаны ясау технологиясе – өч көн. Билгеле, бу вакыт эчендә башка эшләрен дә башкара.

– Әле ярый шушы һөнәрем бар. Кулым эшле, димәк, гаиләм ашлы. Күп эшне үзем башкаргач, акча да янга кала. Өченче ел пандемия вакытында эскәмияләр ясадым. Үзебезнең капканы да яңартасы бар иде. Белешкәч, 75 мең сумга исәпләп чыгардылар. Аны да үзем ясарга тәвәккәлләдем. Нәтиҗәдә, материал өчен 24 мең сум гына китте. Менә шулай аздан да күңел булып, рәхәт итеп яшәү яклы мин, – ди Әлки остасы Ильяс Идиятуллин.

Автор һәм Илдар Әмиров фоторәсемнәре

Ямаширмә авылында – ОСТАХАНӘ-МУЗЕЙ

Зилә МӨБӘРӘКШИНА,
журналист

БЫЕЛНЫҢ МАЙ АЕНДА БИЕКТАУ РАЙОНЫ ЯМАШИРМӘ АВЫЛЫНДА ТАТАР ҺӨНӘРЧЕЛӘРЕНЕҢ МИЛЛИ КУЛ ЭШЛӘНМӘЛӘРЕ ОСТАХАНӘ-МУЗЕЕ АЧЫЛДЫ. МУЗЕЙ-ОСТАХАНӘ ПРЕЗИДЕНТНЫҢ МӘДӘНИ ИНИЦИАТИВАЛАР ФОНДЫ ГРАНТЫ ЯРДӘМЕ БЕЛӘН ТОРМЫШКА АШЫРЫЛДЫ.

«Музей төзелгәнче без зур эш башкардык: фәнни җитәкчебез Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Мәдәният советы әгъзасы, сәнгать фәннәре докторы Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова белән концепция яздык. Биектау, Арча һәм Саба районнары музейлары буенча фольклор экспедицияләр үткәрдек. Җирле мәктәп укучылары һәм мәдәният хезмәткәрләре өчен халык һөнәрләре буенча 12 остаханә оештырдык», – ди музей-остаханә һәм «Туран Арт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять җитәкчесе **Суфия Хәйбрахманова**.

Музей өч зонадан тора: остаханә, «Остазлык мәктәбе» зоналары, авторлык һәм дизайнер костюмнары. Шулай ук биредә эш кораллары, кулдан эшләнгән әйберләр ясауда кулланыла торган материаллар да тәкъдим ителгән. Бүгенге көндә биредә 500ләп экспонат тупланган, музей әлегә сезонлы – майдан алып октябрьгә кадәр эшләячәк.

Суфия ханым Хәйбрахманова әйтүенчә, грант акчасына костюмнар, зәркәннән эшләнгән бизәнү әйберләре сатып алынган, кул эшләнмәләре эшләнгән. Экспозициядә кулдан эшләнгән әйберләр һәм 30 елдан артык эшчәнлек дәвамында тегелгән костюмнар да бар. «Осталарыбыз «Сабантуй» келәме, 90 метрга якын кашага (пәрдә) текте. Шулай ук, тематик-экспозиция планы, агач витриналар эшләнде. Экспозиция авторлары – Елена Гыймранова белән Вера Прокопьева булды», – ди музей-остаханә җитәкчесе.

Бүгенге музей урынында элек Ямаширмә чигү цехы мастеры Радания Гарәфиева җитәкчелегендә кул эшләре остаханәсе булган. «Ул

бу артельнең администраторы, контролеры һәм икътисадчысы иде. Барлык кул эшләре монда башкарылды. Кул эшләре осталары безгә Арча милли аяк киеме җитештерү берләшмәсеннән килде. Хатын-кызлар түбәтәйләр ясау, аларны энҗе белән бизәү, тамбур җебе белән чигү кебек кул эшләрен, каюлы күн (күн мозаикасы) техникасын белә иделәр. Мондагы эшләнмәләр, нигездә, карау һәм өйрәнү өчен», – ди Суфия ханым.

«Алтын тегү һәм колак сыман чигү буенча рәссам Аглая Липина, күн мозаикасы буенча рәссам Светлана Гарбузованы чакырдык. Алар осталарны яңадан укытты, аттестация үткәрде. Идеяләрне тормышка ашыру өчен профессиональ чигүчеләр кирәк иде. Осталар тарафыннан кулдан эшләнгән авторлык эшләнмәләр бөтен дөньяны әйләнеп кайтты. Музейның дәвамы – ишегалдында тирмәдә, өстәмә күргәзмә киңлегендә булачак», – дип, алдагы көннәргә планнары белән дә уртаклашты музей-остаханә җитәкчесе.

Ямаширмә чигү цехы мастеры Радания Гарәфиева элек энә урынына кабан сакалы белән чигүләре турында сөйләде. «Кабан сакалыннан без чүәкләр, читекләр чиктек, аннары гына энә куллана башладык. Кул эшләнмәләре белән кайда гына булмадык: Мәскәүдә дә остаханәләр оештырдык», – ди ул.

Радания ханым тумышы белән Балык Бистәсе районы Котлы Бүкәш авылыннан икән, Ямаширмәгә килен булып төшкән. «Баштан пешекче һөнәрен үзләштердем, авылда пешекче

булып та эшләп карадым – ләкин ул минем һөнәр булып чыкмады. Каен сеңелләрем артельдә эшли иде ул вакытта, алар чиккән әйберләрен өйгә алып кайткач, бала белән утырган мин дә чигү белән кызыксына башладым. Минем дә шушы эшкә өйрәнәсем килде һәм алар мине өйрәтте дә. 1978 елда мин дә артельгә эшкә кердем. Бу минем яратып эшли торган эшем. Коллективыбыз бик актив иде, тырышып, бердәмләшеп, ярдәмләшеп эшләдек», – ди **Радания Гарәфиева**.

Суфия Хәйбрахманова музейдагы кайбер эшләнмәләрнең шәхси коллекцияләрдән сатып алганлыгын да әйтте. «XIX-XX гасырда тегелгән калфаклар, изүләр бар. Шулай ук, пыялада ясалган шәмаил һәм кулдан тегелгән ләүхәләр – шәмаилләр бар. Костюмнарыбыз да бар. Без аларны «Казан ханы» һәм «Казан ханбикәсе костюмнары» дип атадык. Шулай ук, шәһәр һәм авыл татарлары киеп йөри торган костюмнар, чигүле түбәтәйләр, халатлар һәм башкалар бар. Боларның барысы да кулдан тегелгән», – диде остаханә-музей җитәкчесе.

«Бер костюмыбыз Татарстанның һәм Башкортстанның атказанган артисты Элвин Грейга (Радик Юльякшин) дип тегелгән иде. Костюмны Елена Гыймранова эшләде. Тегеп бетергәч, без аны бик ошаттык, шунлыктан, аны үзебезгә коллекциягә калдырырга булдык», – дип тә өстәде Суфия Хәйбрахманова.

Автор фоторәсемнәре

РӘСЕМНӘР БЕЛӘН *чигелгән тарих*

Гүзәл БАХИТОВА,
Чүпрәле районы Мәдәният йорты хезмәткәре

Россия халыкларының мәдәни мирасы елы уңаеннан, 2022 елда Россия картасын кулдан чигәргә тәкъдим ясалган иде. Бу проект тормышка ашты, һәм бик күп ватандашларыбызны рухландырды, һәм иҗади дәвамын алды: илнең 70 төбәгендә, шул исәптән Татарстан Республикасында да, җирле территорияләрнең уникаль чигелгән карталары булдырылды.

Татарстанның чигелгән картасына кертелгән Чүпрәле районы фрагментында аның мәдәни-тарихи, табигый-географик үзенчәлекләре күрсәтелде. Татарстан картасын төзү турында игълан ителгәннән соң, материалны сайлап алу, тарихи мәгълүматларны җыю, рәсем төсен сайлау буенча зур эш башкарылды. Озак фикер алышулардан һәм берничә вариантны караганнан соң, Чүпрәле районы фрагментында аның төп байлыгын – күпмилләтле халкын һәм күп санлы авыл хуҗалыгы культуралары үстерелә

торган уңдырышлы җирен чагылдырырга карар кылынды.

Безнең районда татарлар, чуашлар һәм руслар бик дус һәм тату яши, нәкъ менә шул халыкларның үрнәкләре район фрагментында чагылыш тапты, ә уңдырышлы җире, эскиз ясаганда, алтын бодай формасында күрсәтелде. Эскизның авторлары – Чүпрәле балалар сәнгать мәктәбенең сәнгать бүлеге укытучысы Галина Петровна Захарова белән район Мәдәният йортының халык һөнәрләре буенча методисты Лилия Фиркат кызы Яфизова иде. Бу фрагментны чиккәндә шома чигү техникасы һәм район гербы төсләре кулланылды. Чигешнең авторы – безнең якташыбыз, гаҗәеп оста Татьяна Анатольевна Серебрякова булды. Бик зур иҗади һәм уңышлы эш килеп чыкты. Һәм ул безне районыбызның җентекләп чигелгән картасын ясарга рухландырды. Чөнки һәр авыл җирлегенең территориясе уникаль, үз «визит карточкасы» бар.

Чүпрәле районының җентекле картасы эскизын ясау өчен зур команда җыелды. Аның составына Туган якны өйрәнү музее, Балалар сәнгать мәктәбе, район Мәдәният йорты хезмәткәрләре, методистлар һәм, әлбәттә, авыл Мәдәният йортлары, музей хезмәткәрләре, авылның өлкән яшьтәге кешеләре керде.

Карта ясарга керешкәнче, Чүпрәле районына кергән һәр торак пунктның тарихы җентекләп өйрәнелде. Шуның нигезендә һәр торак пункт территориясе буенча барысына да таныш булган символлар, орнаментлар, фрагментларның төсләр гаммасы билгеләнде.

Мәсәлән, Иске Кәкерленең башка татар авылларыннан аермалы буларак, гаҗәеп бер үзенчәлеге бар: монда данлыклы балта осталары яши. Әлеге һөнәр XVIII гасыр башыннан ук килә. Балта эше белән бер рәттән, такта яру кәсебе дә килеп керә. Безнең осталар чәчәкләп-чуклап төзегән өйләр, каралты-кура, капкалар, күперләр бөтен Россия киңлекләрендә калкып чыга. Шуның өчен дә Кәкерле авыл җирлегендәге картаның төп элементы булып тәрәзә йөзлекләре тора.

Ә 1890 елда Олы Акса авылында төзелгән гыйбадәтханә бик күп дистә еллар дәвамында якындагы округта бердәнбер була. Аның төп байлыгы булып, Иверская Божья Матерь иконасы санала. Нәкъ менә шунда бөтен православие халкы якшәмбе хезмәтләренә килә, анда балалар өчен беренче мәктәп булдырыла. Әлеге гыйбадәтханә бүгенге көндә дә район кунаклары һәм халкы өчен мөһим урын булып тора. Ул да картада үзенең лаеклы урынын тапты.

Б.А. Гафуров җитәкчелегендәге Кече Чынлы авылы җирлеге Татарстан буенча гына түгел, бөтен Россиягә танылган нык һәм икътисади яктан тотрыклы хуҗалык. Карта фрагментында шушы җирлектә булдырылган уңышлар да чагылды.

А3 һәм А4 кәгазьләрендә төсле карандашлар белән эскизлар ясалганнан соң, район мәдәният йортында белгечләр, музей хезмәткәрләре, методистлар, мәдәният йорты директоры һәм мәдәният бүлеге җитәкчесе командасы фикер алышты. Фикер алышу барышында детальләр төгәлләнде, төсләр үзгәрде, кирәкле элементлар өстәлде, артыклары алып ташланды. Бәхәсле моментлар тарихи мәгълүматларга, халык хикәятләренә таянып хәл ителде.

Эскизлар расланганнан соң, рәсемнәрне тукымага күчерү һәм авыл җирлекләрендә осталар тарафыннан чигү процессы башланды. Шома чигү техникасы сайланды, шулай ук кайбер элементлар, тамбур техникасы тегү белән чигелде, ә агачларның сабакларын һәм яфракларын, район исемен язу өчен матур Француз төенчеге кулланылды.

19 авыл җирлегенең әзер эшләнмәләре район мәдәният йортында җыелганнан соң, халык һөнәрләре буенча методист Лилия Яфизова барлык элементларны Чүпрәле районының зур картасына берләштерде. Мондый картаны булдыру өчен идеядан алып, бер тукымага берләштерүгә кадәр ярты ел вакыт китте. Әлбәттә, картаны ясаганда төрле яктан осталар, Казанда экспертлар тарафыннан бирелгән консультацияләр, Татарстанның чигелгән картасын эшләгәндә алган белемнәр ярдәм итте.

Карта халыкка Чүпрәле районы көнендә тәкъдим ителде, ә аннан соң Казан шәһәренең «Мәскәү» мәдәният үзәгендә «Татарстанның мәдәни башкаласы» конкурсының күргәзмә мәйданчыгын бизәде. Хәзер ул район һәм республикакүләм күргәзмәләрнең, чараларның аерылгысыз өлеше булып тора.

Безнең чигелгән карта үзенең сәнгать теле белән районыбызның тарихы, географиясе, мәдәнияте, һөнәрләре турында сөйли һәм, әлбәттә, ул яшь буынны тәрбияләүдә актив кулланыла: чаралар, экскурсияләр, Пушкин картасы буенча мастер-класслар үткәрелә, биредә карта элементлары файдаланыла.

Әлеге карта – варисларыбызга Чүпрәле районының тарихи һәм мәдәни мирасы турында сөйли алырлык иң кыйммәтле әйбер.

Ренат Хәйртдинов фоторәсемнәре

ЙОЛА җырлары

Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,
филология фәннәре докторы, доцент,
Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш фәнни хезмәткәре

ҖЫР – ЙОЛА ФОЛЬКЛОРЫНЫҢ БИЗӘГЕ

Фольклор әсәренең төп билгеләреннән берсе – синкретиклык. Катлаулы күренештән гыйбарәт йола фольклоры эчендә очрый торган җыр текстлары – әнә шул җитди билгенең күркәм мисалы. Йола фольклоры поэзиясе һәм уен-бию җырлары – җыр жанрының йола яки уен барышында реальләшә торган төре. Нәкъ менә шушы аерылгысыз бәйләнештә булу сыйфаты, ягъни күптөрле нәүрүзләрнең һәм келәүләрнең, арбауларның һәм сыктауларның, такмак-такмазаларның һәм җырларның теге яки бу йола, уен барышына логик һәм эстетик бәйләнгән булуы, аларның шул бәйләнештән башка җанлы яшәештә бик сирәк очравы – бу катлаулы иҗат дөньясының уртак сыйфаты, асыл сыйфаты.

Йоладагы җырны һәрвакыт җыр тексты буларак аерып карап булмаска да мөмкин, кайбер очракта җыр тексты йола фольклорында эреп беткән, өзек-өзек кисәкләрдән генә гыйбарәт, яисә тиешенчә сакланмаган була. Әйтик, ел фасылына мөнәсәбәтле язны, җәйне, көзне, кышны каршылау яки озату белән бәйле йолалар составындагы җырларны, үз вакытында язып алмау, теркәлеп калмау яисә башка сәбәпләр аркасында безнең көннәргә тулысынча килеп җиткән дип әйтеп булмый. Алай да җыр жанры билгеләренә бик якын торган, чагыштырмача тулы, күләмле поэтик бөтеннәр дә бар.

Йола җырларының өйрәнелү тарихын да күп катламнардан торган йола фольклорыннан аерып карап булмый. Йола поэзиясенең, тагын да гомумирәк итеп алганда йола фольклорының аерылгысыз атрибуты буларак, йола җырлары турында беренче мәгълүматлар К. Насыйри хезмәтләрендә урын алган булса, соңгырак чорда мәсьәләнең күп кенә яклары Н. Исәнбәт, Х. Ярми, И. Надиров, М. Нигъмәтҗанов, Р. Мөхәммәтҗанов, М. Мәһдиев, М. Бакиров, Д. Рамазанова, Ф. Баязитова, Ф. Урманчеев, К. Миңнуллин һәм башкалар тикшеренүләрендә яктыртылды. Галимнәрнең игътибар үзәгендә йолаларның күбрәк поэзиягә караган өлеше, сүз белән бәйле фольклор тора.

Башка барлык халыклардагы кебек үк, бездә дә бала туу, кешенең өйләнүе һәм үлүе белән бәйләнгән гореф-гадәтләр, һәртөрле йолалар һәм шуларга карата иҗат ителгән әсәрләр шактый күп булган. Чыннан да, Идел буе Болгарында, мәсәлән, үлгән кешене соңгы юлга озатканда ир-атлар тарафыннан елау-сыктау җырлары башкарылган. Бу хакта Ибн-Фадлан

Информантлар йола җырлары башкару вакытында. Ютазы районы, 2023 ел

язмаларында мәгълүмат бар (Путешествие Ахмеда Ибн-Фадлана на реку Итиль и принятие в Булгарии ислама. Древний текст пересказал С.Шамси. М.: «Мифи-Сервис», 1992, С. 42-43). Ислам таралу белән мондый һәм башка шундый йолаларга әкренләп чик куелган, кешенең кайгы-хәсрәте белән бәйле әлеге төр поэтик иҗатның күбесе онытылган.

ТУЙ ЙОЛАСЫНДА ҖЫРЛАР

Гаилә-көнкүреш йолалары арасында иң күренеклесе – өйләнешү (никах) туе белән бәйле поэтик текстлар. Йолаларга мөнәсәбәтле җырларның иң яхшы сакланганнары – туй йоласы җырлары, араларында хәтта бик борынгыдан безнең көннәргә килеп җиткән мисаллар да юк түгел. Туй йоласы җырлары йола фольклорында аеруча киң таралган ядкарьләр булуы белән дә әһәмиятле.

Туй йоласы җырларының безнең көннәргә килеп җиткәннәрен кыз елату җырлары, сыктаулар, ишек бавы, кияү каршылау, кыз озату, килен төшерү, туй мәҗлесе җырлары дигән тематик төркемнәргә бүлеп карарга мөмкин. Мәгълүм булганча, татар халкының туй йоласын бер-берсенә тыгыз бәйләнгән өч өлешкә бүлеп йөртәләр: беренчесе – туй алды (моңа яучылау, килешү, билге алышу, ярәшү кебек йола-гадәтләр керә); икенчесе – туй үзе (никахны рәсмиләштерү, кыз һәм егет ягында туй үткәрү белән бәйле гореф-гадәтләр); өченчесе – туй арты (килен төшерү, шәл салдыру, кода төшерү, кияү кайтармасы һәм башка) йолалары. Зур йоланың төрле этапларында башкарылып, сүз сәнгате буларак эстетик югарылыгын саклап безнең көннәргә килеп җиткән җыр текстлары бар.

Татарлар – сибелеп яшәүче халык. Урынына-ягына, авылына-тирәлегенә карап, туйлар төрле җирдә төрлечә үткән. Казан тирәсендә яшәүче татарларның туйлары белән Мордовия Республикасы яисә Түбән Новгород өлкәсендәге мишәрләрнең туйлары, ислам дине, шәригать кануннары катнашкан туйлар белән керәшен татарларының туйлары арасында күп кенә аерымлыклар табарга була. Бу – тарих һәм көнкүреш, җирле шартлар һәм тирә-юньдәге элемтә-йогынтылар белән бәйләнгән табигый бер хәл. Шул ук вакытта туй йоласында татар халкының барлык этник төркемнәренә дә хас булган уртак, гомуми гадәтләрне дә күрми калмый мөмкин түгел. Тарихның түренәрәк киткән саен йоланың традицион бердәмлек сыйфатлары күбрәк ачылып, аерымлыклар исә безнең гасырларга якынайган саен ныграк сизелә.

Жанр төрләре күзлегеннән караганда, туй поэзиясе шактый катлаулы. Лирик, драматик төсмерле «Кыз елату» җырлары белән бергә, бу поэзия хәзинәсендә туйда яучылар тарафыннан әйтелә торган кинаяле такмазалар да, теләк әйтүгә юнәлгән арбаулар да, мактау җырлары да, чәнечкеле шаян такмаклар да очрый. Аларның һәркайсының үзенә генә хас стилистик формасы бар, башкару алымнары да төрле. Ялгыз җырлауга исәпләнгән лирикадан тыш, диалогка корылган яки күмәк җырлана торган әсәрләр шактый. Туйның эчке логикасына буйсынып, аларның я берсе, я икенчесе башкарыла. Туй поэзиясенә кергән әсәрләрнең аулакта яисә мәҗлес вакытында гына түгел, йола таләбе кушуынча, капка төбендә, ак келәт янында, ишек төбендә, тәрәзә яисә бусага алдында җырлануын да әйтеп үтәргә кирәк.

ТУЙ АЛДЫ ГАДӘТЛӘРЕНЕҢ БЕРСЕ – КЫЗ ЕЛАТУ

Яучы белән сөйләшү-килешү йоласы үтәлгәннән соң, китәчәк кызны иптәшләре-тиңдәшләре озатырга киләләр. Кызның чәченә тәңкәләр үрелә, башына тастар кидерелә, өстенә ак бөркәнчек каплана. Шул чагында махсус җырлар – «Кыз елату» җырлары башкарыла. Алар кияүгә бирелгән кыз һәм аның дус-ишләре, ә кайбер очракларда йоланы әйбәт белүче берәр карчык тарафыннан җырланган. Җырларның төп эчтәлеге кызның туган йорты, әти-әнисе, туганнары, яшьлеге һәм кыз чагы белән саубуллашуга кайтып кала. Кыз елату йоласы мишәрләр яшәгән төбәкләрдә, керәшен һәм Себер татарлары арасында аеруча нык таралган була. Кыз елату йоласының безнең көннәргә килеп җиткән мисалын Чиләбе өлкәсе Нязепетровск районына карый торган татар һәм татар-башкорт авылларында очратып, язып алырга насыйп булды. Чиләбе өлкәсе Нязепетровск шәһәрендә Гөлнур Хәмидулла кызы Рәхмәтуллинадан (1953 елгы, тумышы белән Арыслан авылыннан) берничә берәмлектә язып алынган бу җырларны информант үзе «Чеңләү җырлары» дигән исем белән атый.

Кыз елату җырларының эчтәлегенә һәм эмоциональ яңгырашына тирән трагизм хас. Төрки халыклардагы кыз елату җырларының тамыры теге һәм бу дөнья хакындагы бик борынгы мифологик күзаллауларга барып тоташу ихтималы зур. Кыз елату җырларының иң зур күпчелеге кайгы-хәсрәт, күз яше белән сугарылган. «Әрнеп кенә, сызлап елыймы», «Бикләдегез тимер йозакка», «Ничек ят өйләрдә торырмын» – бу һәм башка җырларның исемнәрендә үк тирән сагыш, билгесезлектән курку, кире кайтарып алып булмаслыклык югалту хисе, кияүгә китүне зур бер афәт белән тиңләштерү бар.

Кыз елату җырларының күпчелеге импровизация катнашында иҗат ителгән. Бу табигый да. Чөнки һәрбер ярәшелгән кызның шәхси язмышы үзенә аерым. Элек иҗат ителгән һәм гомум-уртак эчтәлектәге җырларга һәрбер кыз үз язмышына, үзенең шул вакыттагы халәтенә хас үзенчәлекләрне дә өстәгән. Шул рәвешле, аларда импровизация белән традицион поэтика тыгыз үрелгән. Әмма структур яктан бу үрелештә традиционлык катламы шактый көчле булып, индивидуаль иҗат катламы сизелер-сизелмәс бизәкләр төсендә генә гәүдәләнә. Чөнки традицион поэтикада сагыш, үпкә, кайгы, өмет тойгыларын сурәтле итеп калыпка салган образлар үзәк урынны алып тора. Икенче яктан, йоланың үз кануннары белән чикләнгән эчке ситуациясе индивидуаль иҗатка артык иркенәеп китәргә мөмкинлек бирми.

Елату җырларының төп шигъри формасын дүрт юллы строфа тәшкил итә. Арада берничә җыр гына кушымталар хисабына биш-алты юллы строфаларга үстерелә («Ах, кәбәм, анакай»; «Тудыкайлар»). Ритмик-интонацион яктан борынгы дастан строфаларын хәтерләтүче җырлар да бар. Аларда бер-берсенә мәгънәви һәм шигъри бәйләнгән тезмәләр саны һаман үстерелә һәм чылбырлы озын строфа барлыкка килә.

ЙОЛА ФОЛЬКЛОРЫ КОМПЛЕКСЫНДА «ЯР-ЯР»ЛАР

«Яр-яр» җырлары – кыз елату җырларының үзенчәлекле төркеме. Кайчандыр шәкертләр арасында «Яр-яр» стиленә таянып язылган мәхәббәт шигырьләре дә таралган була. Тарихи-генетик яктан «Яр-яр» әйтү гадәтен күп кенә төрки халыкларның туй йоласына хас уртак гадәт дип саныйлар. Аның бер төркем җырлары борынгы «Бүз егет» дастанында китерелгән.

Үзбәкләрдә һәм төрекмәннәрдә аны «Яр-яр», казакъларда «Жар-жар», ногайларда «Хей-жар», каракалпакларда «Хау-жар» дип йөртәләр. Нигездә исә «Яр-яр» җырларының төп рухы гаилә юлына аяк баскан яшьләрне котлауга, мактауга, теләк-киңәшләр әйтүгә, кызның күңелен күтәрүгә юнәлгән. Шуңа күрә кызның җиңгәләре, дуслары, кияү егетләре башкарган җырларда тантаналылык хисе өстенлек итә:

Берең энҗе, берең мәрҗән,
Берегез бер гөл, берегез былбыл,
Тезелепсез, яр-яр; Бер булыгыз, яр-яр;
Берең тутый, берең былбыл,
Яктылыкта яшәгәндә
Кушылыпсыз, яр-яр.
Аерылмагыз, яр-яр.

ИШЕК БАВЫ ҖЫРЛАРЫ

Туй йоласы җырларына караган «Ишек бавы» җырлары – йола поэзиясендә аерым бер урын алып тора торган төркем. Әлеге җырларда халыкның ячылау, елату, «Яр-яр» әйтүләрдән соң үтәлгән бер гадәте сурәтләнә. Ул гадәт кияү кертүгә караган. Аның бердәнбер тулы тексты үз вакытында Г. Тукай тарафыннан Уральск яклрында язылып алынган. Җыр сюжеты балаларның кәләш янына керәсе кияүне ишек төбендә туктатып, аңардан көмеш акча соравына, шул рәвешле шаян рухта сатулашып, кәләшнең бәясен күтәрүгә корылган. «Ишек бавы» җырлары лексикасында гарәп-фарсы сүзләре, дини төшенчәләр (җәннәт капкасы, хур кызы) еш очрый. Туй йоласына мөнәсәбәтле җырлар арасында кияү каршылау, кыз озату, килен төшерү белән бәйле җырлар да әһәмиятле урын били.

ТУЙ МӘҖЛЕСЕ ҖЫРЛАРЫ

Туй йоласы поэзиясенең тагын бер зур төркеме – туй мәҗлесе җырлары. Кыз ягында да, кияү ягында да туй мәҗлесе кодалар, туган-тумачалар, дус-ишләр катнашы белән уздырылуы – гадәти хәл. Кайсы гына төбәктә булмасын, татарларда андый мәҗлесләр җыр-биюсез, уеннарсыз үтмәгән. Казан татарлары һәм мишәр татарлары туйларында, гадәт буларак, туганлык-кардәшлекне ныгытуга багышланган җырлар, гомум репертуардагы традицион

Йола җырлары җырлап күрсәткән информантлар янында. Азнакай, 2019 ел

мәҗлес һәм лирик җырлар төп урынны алып торганнар. Керәшен татарларына килсәк, анда хәл башкачарак. Аларның туйларында туй барышы белән тыгыз бәйләнгән махсус җырлар әүвәл дә, хәзер дә киң таралган, ә җырлашып утыру туйның күркәм бер гадәте итеп санала:

Кодалар, кодагыйлар, кодачалар арасындагы поэтик диалог үзәгендә бер-берсенең нәсел затын, байлыгын, аш-суын, кызның бирнә-бүләкләрен, яшьләрнең буй-сынын, холык-фигылен мактау тора:

Алтыннардай инде егетебез,
Көмешләрдәй икән кызыгыз.
Алтыннардай булса, уалмас,
Көмешләрдәй булса, җуелмас.

Бал салмаган кисмәкләргә
Балавызлар каян ябышкан?
Берегез нәфис, берегез – купец,
Сез кайлардан болай табышкан.

Йола җырларында традицион поэтикага киң урын бирелгән: егет «болан кебек җитез», «кая барса мактаулы», «алтын акыллы», «авылда бер дигән», ә кыз исә «оҗмах эчендәге

Информантлар йола җырлары башкару вакытында. Ютазы районы, 2023 ел

фәрештәдәй», «нәфис гөл кебек», «буй-сыннары камыштай зифа», «асыл кошка тиң» һәм башкалар. Мактау белән бергә туй мәҗлесендә шаян җырлар да, хурлау җырлары да яңгыраган. Аларның вазыйфасы нигездә дусларча үртәшүгә, үпкә белдерешүгә, көнкүрештә очрый торган комсызлык, шапырыну кебек тискәре сыйфатларны тәнкыйтьләүгә кайтып кала. Гадәттә, ул җырлар егет белән кыз адресына түгел, ә туйга җыелган туган-тумачаларга юнәлтелә («Туйда хурлашу җырлары», «Бирнә сорау җырлары» һәм башкалар).

ЕГЕТ ЙОРТЫНА КИЛЕН ТӨШЕРҮ ҖЫРЛАРЫ – АРБАУЛАР

Егет йортына килен төшерү шәлкеменә килсәк, бу йолада төп рольне кияү егетләре уйнаган. Аларның килен белән кияүгә багышланган күмәк җырлары, йола кануннары буенча урамда, капка алдында, яисә ак келәт янында башкарылып, яшьләргә мәхәббәт һәм тигез гомер теләүгә кайтып кала. Кияү йортына килгән яшь киленгә теләкләр әйтүнең махсус шигъри формасы да булган. Ул «Арбау» исеме белән мәгълүм. «Арбау әйтү» – халыкның гаилә коруга, аның нигезен ныклы итүгә багышланган күркәм бер гадәте. Стиль, поэтикасына караганда, «арбау»ны килен төшкән көнне махсус башкаручыдан – өлкән яшьтәге хатын-кыздан әйттергәннәр, каенананың да арбау әйтү очраклары булган.

Киленгә багышлап арбау әйтү гадәте ерак чорлардан килә. Борынгы йолалар буенча, килен каената йортындагы тәртип-кагыйдәләрне бик әйбәт белергә, аларга буйсынып яшәргә, гаилә алдындагы вазыйфа-бурычларына хилафлык кылмаска тиеш булган. «Арбау»лар яшь киленне әнә шул кагыйдәләр белән таныштыру хезмәтен үтәгәннәр. Бу ритуал төрки халыкларның күбесенә мәгълүм. Казакъларда, каракалпакларда аны «биташар» (бит ачу) дип йөртәләр. Киленгә теләк-нәсихәт рәвешендә озын-озын җырлар әйтелгән:

Исән генә килдеңме, балам,
Ак күңелдән сиңа арбау салам:
Төкле аягың белән, талмас кулың,
Таймас табаның белән кил!
Юраганың юш булсын!
Курыкканың буш булсын!
Җиләктәй җиде матурың тусын!
Җиденең җефәктәй изгелеген күреп картай!

Татарларда кияүгә атап әйтелгән «арбау»лар да булган. Аның эчтәлеге асылда шул ук, ул кияүгә яраклаштырып әйтелгән теләкләрдән тора.

Йола җырлары әһәмиятле мирасмы?

Татар халкының йола фольклорына караган җырлары йола һәм аның гамәли функцияләреннән аерылгысыз бер хәлдә яшәмәгәннәр. Заманнар узу белән бу поэзиянең йолачылык хасиятләре юкка чыга барган һәм туйга мөнәсәбәтле әсәрләр, күбрәк эстетик вазыйфа үтәп, шигъри бизәкләр төсен алганнар, шуңа карамастан бу төркем әсәрләрнең туй йоласы белән бәйлелеген таныта торган билгеләр югалып бетмәгән. Шул ук вакытта халыкның йола поэзиясе үрнәкләрен бүгенге көндә дә очратырга мөмкин. Традицион йола поэзиясе халыкның шигърият байлыгын үзенә туплаган бай һәм үзенчәлекле чыганак булуы белән әһәмиятле. Йола фольклоры җырлары халыкның рухи культурасын, иҗтимагый һәм гаилә-көнкүреш мөнәсәбәтләрен өйрәнү җәһәтеннән дә билгеле бер функция үти. Милли тарихыбызны тергезүдә йола җырлары – филолог-фольклорчылар өчен генә түгел, тарихчылар, телчеләр, этномузыкологлар өчен дә кызыклы чыганак.

Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан

Мифлар каян барлыкка килгән

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ,
язучы, әдәбият белгече

Мифлар – борынгылар өчен тормышны, чынбарлыкны, табигатьне кабул итү, танып белү һәм аңларга тырышу чарасы булып хезмәт иткәннәр һәм ихлас ышануга нигезләнгәннәр. Борынгы мифологик күзаллаулар нигезендә *анимизм* (һәр табигать күренешенең иясе, рухы, заты, алласы бар дип тану), *тотемизм* (хайваннарны аллалаштыру) һәм *фетишизм* (әйберләргә табыну) тәгълиматлары ята.

Һәр мифологиянең нигезен тәшкил иткән мифларны берничә төркемгә бүлеп карарга мөмкин: Галәмнең һәм Дөньяның яратылышы һәм төзелеше хакындагы текстлар *(космогоник мифлар)*, тереклек дөньясы, хайваннар һәм үсемлекләр белән бәйле ышанулар *(анимистик, тотемистик, зооморф мифлар)*, кеше яратылышы хакындагы ышанулар *(антропогоник мифлар)* һәм башкалар. Шулай да, һәрбер мифологик системаның аны оештырып, тотып торучы мөһим бер үзәге, «умыртка сөяге» бар. Ул – Галәм һәм Табигать, Тереклек һәм Кешелек дөньялары белән идарә итүче, Кешенең яшәешен, рухиятен үз ихтыярында тотучы *аллалар сыйныфы*, аларның Күктәге, Җирдәге, Һавадагы, Судагы иярченнәре белән бәйле ышанулар.

Кешелек тарихының ыру-кабиләчелек чорында ияләр, рухлар, аллалар ничек барлыкка килә соң? Ыру-кабиләләрнең аң-белем дәрәҗәсенә, дөньяны танып-белү ысулларына карап, берничә юл белән барлыкка киләләр. Борынгырак дәверләрдә кеше һәр табигать күренешен беек сер, тылсым итеп кабул итә һәм бу сер-тылсымнан илаһилык эзли, аны изгеләштерә, аллалаштыра. Шул рәвешле башта берәр нәрсәгә, утка, суга яисә гади генә агачка, куакка, хәтта үләнгә табына, аннары кош-җанварларны, хайваннарны илаһилаштыра, аллалаштыра башлый.

Кеше үзенең табигатьтә, тереклек дөньясында, хәяттә тоткан урыны хакында күбрәк уйланган саен, үзенең өстенлегенә ныграк ышана барган саен, үз аллаларын (тотемнарын) шулкадәр күбрәк сынландыра, җанландыра, кешеләштерә (затлаштыра) бара. Һәм аның рухи дөньясында табигатьтән дә аерылып бетмәгән, әмма инде кеше сыйфатларына да ия булган аллалар, ияләр, рухлар, мифик затлар килеп керә. Алар инде табыну объекты гына түгел, бәлки, үзләре дә кешеләргә тәэсир итә алалар: йә изгелек кылалар, йә зыян салалар...

Шул рәвешле, кеше үзаңда өр-яңа баскычка күтәрелә: элегрәк табынган агач (урман)ның яисә елга (су)ның үз иясе барлыгына ышана башлый. Әмма аның аңы ярым адәми, ярым табигый затлар

дәрәҗәсендә калса, гаҗәп тоелыр иде. Бәхеткә, кеше үз күңеле һәм акылы белән бөтен җир тормышын, җир асты һәм күк дөньяларын илаһи ихтыярына буйсындырып торган затны – Бердәнбер Алланы сизенә, тоя алган. Ул – Бөек Тәңре. Византия тарихчысы Феофилакт Симокат түбәндәгеләрне хәбәр итә: «Төркиләр барыннан да элек утны хөрмәт итәләр, һаваны, суны олылыйлар, җиргә дан җырлыйлар, – ди ул. – Ә шулай да Күкне, Җирне яраткан Берәүгә генә табыналар һәм аны Тәңре дип атыйлар». Рухи дөньяда Күк Тәңре әнә шулай барлыкка килә.

«

Борынгырак дәверләрдә кеше һәр табигать күренешен бөек сер, тылсым итеп кабул итә һәм бу сер-тылсымнан илаһилык эзли, аны изгеләштерә, аллалаштыра.

«

Тәңречелекне мәҗүси ышанулар җыелмасы дип кенә карау дөрес булмас иде. Һәрхәлдә ул һуннар чорында ук төзек, эзлекле дин буларак күз алдына килеп баса. Һәртөрле мәҗүси ышанулардан аермалы буларак, бу диннең илаһи иерархиясе төгәл билгеле: Баш Тәңре (Күк Тәңре) – югары һәм кече тәңреләр (аллалар) – рухлар-ияләр (алар үзләре изге (югары) рухларга һәм явыз (түбән) рухларга бүленәләр) – ярым илаһи затлар (алыплар, бабалар, аталар, аналар, ирәннәр һәм башкалар) – әүлияләр, им-томчылар, шаманнар...

Төп Тәңрене төрлечә атап йөрткәннәр: Югары Алла, Баш Тәңре, Бөек Тәңре, Күк Тәңре (Кок Тәңре), Тәңре-Хан (Тәңрехан), Күк иясе, Күк хуҗасы, Ходай (Кодай), Изи (Иги) һәм башкалар. Аны төркиләр кеше сыйфатларына ия булган илаһи зат, алла рәвешендә күзаллыйлар. Болгар галиме А.О. Стойнев борынгы төркиләр һәм Дунай болгарлары хакындагы чыганакларны тикшергәннән соң шундый нәтиҗәгә килгән: «Тәңре күренми торган антроморфланган (кешеләштерелгән – *Г.Г.*) ир-ат буларак күз алдына килә; атрибутлары: күк, кояш, ат, бөркет; вазифалары: хәрби хезмәт, иҗат эше, хуҗалык эшләре, хокук хезмәте (хаклык, кешелек язмышын кулга алу, саклау-яклау, куркыту, хөкем итү, бүләкләү), дини-үзаң...».

Тәңречелек тәгълиматы буенча, баш Тәңрегә ике кече тәңре – Җир-Су (Изге Йер-Су, Йерсу) һәм Умай (Ымай, Омай) дигән тәңреләр буйсына. Аларның беренчесе җирдәге, судагы бөтен тереклек һәм матди дөнья белән идарә итсә, Умай тәңребикә, якты дөньяга туганда ук һәр кешенең җан-үзәгенә үтеп кереп, кешелек дөньясы, аның рухияте белән идарә итә. Ул нигездә адәми затлардагы рухи башлангычны белдерә, кешенең рухи һәм физик бөтенлеген, асылын, егәрлеген саклый. Җир йөзендәге яшәеш менә шушы ике алла (тәңре) кулында. Алар бөтен өч дөнья белән дә үзләренә буйсынган ваграк аллалар (тәңреләр), рухлар, ияләр, мифик затлар аша идарә итәләр.

Күк Тәңре, Җир-Су, Умай тәңреләрнең борынгы төркиләр күзаллавында «югары аллалар» пантеоны тәшкил итүе Орхон-Енисей язмаларында ук ачык чагылыш тапкан. Күл-тегиннең VII гасырга караган Кече язуында Төньюкукка багышланган шундый юллар бар (хәзерге телгә тәрҗемәдә китерелә): «Алар (дошманнар) шикләнмиләр дә, Күк, Умай, Изге Җир-Су безне каргаячак, уйларга кирәк!»

Тәңречелек тәгълиматы буенча, аллаларның өченче баскычы – кече (түбән) тәңреләр сыйныфы. Галәмдәге, шул исәптән Күк, Җир өсте, Җир асты дөньяларындагы һәр нәрсәнең, күренешнең үз тәңресе булуы хакында халык ышануларында да, язма әдәбиятта да җитәрлек мәгълүмат сакланып калган. Мәсәлән, Ибн Фазлан үзенең «Сәяхәт...»ендә язган: «Төркиләр, – ди ул, – унике раббе барлыгына ышаналар вә Кыш, Җәй, Агач, Адәмнәр, Хайваннар, Су, Кич (Ай), Көндез (Кояш), Үлем, Тереклек, Җирләрнең – һәрберсенең үзләренә хас раббылары булып, Күктә булган Раббы һәрберсеннән олыдыр; шулай булса да, бу олы Раббы башка раббыларның катнашында һәм киңәшләре белән эш итә».

Башка кайбер чыганакларда борынгы болгар бабаларыбыз мифологиясендә, Югары Алла – Күк Тәңредән кала, уналты кече тәңре булганлыгы искәртелә. Алар түбәндәге рәвештә парлап санала (һәр илаһи көчнең антиподы, илаһи гармонияне тәэмин итү өчен кирәк булган пары булырга тиеш дип ышанганнар): Кояш тәңресе – Ай тәңресе; Ут тәңресе – Су тәңресе; Көн тәңресе – Төн тәңресе; Агач (Урман) тәңресе – Кош-корт, хайван-җәнлек тәңресе; Һава (Җил) тәңресе – Җир тәңресе; Күкрәү тәңресе – Яшен тәңресе; Яңгыр тәңресе – Корылык тәңресе (Чиллә); Тереклек (Яшәү) тәңресе – Үлем тәңресе. Бу очракта да, Җир-Су белән Умайга тиешле вазифаларны алсак, Көн һәм Кояш тәңреләрен, Кич һәм Ай тәңреләрен берләштерсәк, шул ук унике кече (түбән) тәңредән торган түбән аллалар сыйныфына юлыгабыз...

Тәңреләр – күкләр ихтыярында яшәүче илаһи көчләр, дидек. Күк Тәңре Җирдәге яшәеш, Табигатьтәге күренешләр белән шушы илаһи көчләр аша элемтәгә керә, алар ярдәмендә үзенең изге-илаһи яки шомлы-куркыныч гамәлләрен башкара.

Ә менә бүген укучы кулына килеп кергән әлеге язмада сурәтләнгән мифик персонажлар – җир өстендәге, кешелек дөньясындагы яшәеш барышына тәэсир итәргә тырышучы рухи затлар. Аларның бер өлеше (югары рухлар), тәңреләрнең җир йөзендәге вәкилләре булган иярләр сыйныфына берләшеп, кешеләр белән татулыкта яшәргә тырышса, икенчеләре, изгелек-илаһилыктан ерагаеп, күп очракта, шайтани затлар кебек, тәңреләр тарафыннан җиргә сөрелеп, түбән рухлар сыйныфы барлыкка китергәннәр.

«Төп Тәңрене төрлечә атап йөрткәннәр: Югары Алла, Баш Тәңре, Бөек Тәңре, Күк Тәңре (Кок Тәңре), Тәңре-Хан (Тәңрехан), Күк иясе, Күк хуҗасы, Ходай (Кодай), Изи (Иги) һәм башкалар.«

ӨЙ ИЯСЕНЕҢ ИЗГЕЛЕГЕ

Сырхау анасы белән генә бер кыз яшәгән. Анасы авыру булгач, ул кияүгә дә чыкмаган, дус кызлары белән дә аралашмаган.

Бервакыт урам буйлап бер имче карчык узып бара икән. Кыз аның янына йөгереп чыккан да анасын дәвалап карарга өенә чакырган. Имче карчык кызның сүзен аяк астына салмаган, авыру хатын янына кергән. Түшәктә яткан анага күз сирпеп кенә алган да әйткән:

– Анаңны терелтә алам, тик син моның бәрабәренә ике күзеңне бирергә тиеш буласың, – дигән.

– Бирәм, бирәм, анамны гына аякка бастыр, – дигән кыз.

Имче карчык авыру ананы имләп терелткән дә, кызның ике күзен алып, үз юлына китеп барган. Сукыр кыз анасы белән бергә матур гына яши башлаган. Күзләре күрмәсә дә, аның җаны тынычланган – газиз анасы терелеп аякка басты бит! Егылып, бәрелеп, бөтен тәнен күгәртеп бетерсә дә, ул эченнән генә сөенеп, куанып туя алмаган.

Менә хикмәт: сукыр кыз торган өй идәне астында үз гаиләсе белән Өй иясе яшәгән, имеш. Кыз бәрәр нәрсәгә абынып егылган саен астагы иярләр дөньясы дер селкенеп ала икән. Иярләр тормышында тынычлык беткән. Өстәге дөбердәвек тавыштан алар нишләргә дә белмәгәннәр.

Өлкән Өй иясе, иң акыллы, иң зирәк якыннарын үз тирәсенә җыеп, киңәшләшә башлаган. Ниһаять, бер карарга килеп, рухлар үз почмакларына таралышканнар. Ә Өй иясе үзе сукыр кыз янына менеп киткән.

Кыз бу вакытта җеп эрләп утыра икән. Үзе моңлы итеп җырлый, ди:

Күңелемне ачып
бирим әле,
Күңелемдә минем
моңнар бар.
Бу җырымны бөтен
дөнья тыңлар,
Бу җырымны җилләр
тыңларлар...

Шулвакыт кызның колагына ят бер тавыш ишетелеп калган:

Бу җырыңны иярләр тыңларлар...

Кыз, сискәнеп, сикереп үк торган:

– Кем бар монда, кем бу? – дип өзгәләнгән ул. Беркем дәшмәгән.

– Әнием, син шаяртасыңмы әллә?

Бу юлы да беркем тавыш бирмәгән. Бераздан, йомшак җил сулышы бәрелгән кебек кенә, кызның колагына пышылдау тавышы ишетелгән: «Капканы чыгып уң якка борылсаң, авыл читендәге күперне узып, үргә күтәрелсәң, ике тау куенында саркып яткан билгесез чишмәгә юлыгырсың... Шуның суы белән күзләреңне ю... Юганда моңлы җырыңны җырла. Тик аны «Күзләремне ачып бирим әле...» дип башла, «Бу җырымны иярләр тыңларлар» дип бетер... Барысын да шунда аңларсың...»

Кыз баштарак куркып, шикләнеп калган. Әмма аның бик тә күзле, якты дөньялы буласы килгән. Ул нәкъ Өй иясе әйткәнчә эшләгән: капшана-капшана капкадан чыгып, уң якка киткән, сак кына басып, авыл читендәге күперне узган, үрмәләп менеп, тау куенындагы билгесез чишмәне барып тапкан... Аннары, тезләнеп, кушучлап су чумырып алган да битенә, күзләренә сирпегән... Үзе моңлы итеп җырлаган:

Күзләремне ачып бирим әле,
Күзләремдә минем моңнар бар.
Бу җырымны бөтен дөнья тыңлар,
Бу җырымны иярләр тыңларлар...

Шулвакыт аның күз алдында кабат якты дөнья ачылып киткән. Кыз тагын күрә башлаган. Аның

моңлы дөньясына тагын шатлык, дәрт, өмет кереп тулган... Ул инде үткән-сүткәндә өстәл-урындыкларга бәрелмәгән, егылып та интекмәгән, кул-аякларын да җәрәхәтләмәгән.

Иң мөһиме: идән астындагы Өй иясе дә тыныч гомер сөрә башлаган. Кыскасы, дөнья тигезләшкән, күңелләргә изгелек, күзләргә нур иңгән...

ҖИР ЯРАЛУ

Болгар бабаларыбыз уйлавынча, Җир Дәрья төбеннән чыккан балчыктан яралган.

Бик борынгы заманнарда, әле Җир дә, Кеше дә булмаган вакытларда, бар Дөнья судан гына торган, ди. Кая гына бакма, бар җирдә Дәрья-су булган, давыллар уйнаган, дулкыннар күккә бәйләнгән...

Дәрьяда Тәңре кошлары – мәһабәт үрдәкләр йөзеп йөргән. Алар су төбенә төшеп, азык эзлиләр икән. Тәңре Җирне яратмакчы булган. Шунда бер Үрдәк Дәрья төбенә чумган да томшыгына азык алырга теләгән. Томшыгын тирәнгәрәк батырганмы, ул су төбеннән бик күп ләм-җир күтәреп алып чыккан. Бу ләм шулкадәр күп булган ки, хәтта, әлеге Үрдәкнең томшыгыннан коелып, су өстендә комлы-ташлы Җир-утрау булып өелеп калган. Имеш, коры Җир әнә шулай барлыкка килгән.

Соңрак Җир-утраудагы йомшак ком-туфрактан – яхшы кешеләр, ә ташлы-кәсле балчыктан явыз затлар яралган, имеш...

ТЕГЕРМӘНЧЕ ҺӘМ СУ АНАСЫ

Кайчандыр бер буада су тегермәне торган. Аның хуҗасы Кәрим исемле булган. Гаиләсе булмаган, хезмәтче итеп күрше авылдан бер ятим малайны тоткан. Бик әйбәт барган моның эше. Тирә-яктагы авыллар бөтен ашлыкларын шушы тегермәндә тарткан. Һәр кеше бер куш уч кына он калдырса да, болар ел буе туйганчы ашап, борчу-кайгы белмичә яшиләр икән.

Корылык елларда, тегермәннән кеше өзелгән чакларда, буада балык тотып тамак туйдыралар икән. Ләкин бер бик сәер балык эләккәннән соң тегермәнче балык тотуны ташларга мәҗбүр булган. Кеше башлы бу балыкны ул кая куярга белмәгән, ахыр чиктә, кире буага җибәрергә булган, әмма әлеге җан иясе суга барып җиткәнче җан тәслим кылган, һәм аны буаның ерак бер почмагына кабер казып күмгән.

Шуннан соң башланган да инде тегермәнче тормышында авыр көннәр. Су анасы бик җәфалый икән аны. Әле тегермән куласасына көчле дулкыннарын җибәреп, су улакларын ватып бетерә, әле шул ук куласаны кирегә әйләндерә башлый, ди. Бераздан бу су заты, артыннан озын, юеш чәчләрен сөйрәп, тегермәнче янына килеп үзе дә килеп җиткән.

– Син минем баламны алдың, хәзер инде үз малаеңны бир! – ди икән.

Тегермәнче шунда гына аңлап алган – кеше башлы балык шушы Су анасының баласы булып чыга ласа!.. Ләкин ул хезмәтче малайны бирергә уйламаган да. Кеше баласына хуҗа була алмый ла ул. Үз баласы булса, бигрәк тә бирмәс иде. Юк, юк, бу турыда сүз дә булырга мөмкин түгел...

Су анасы көн саен килә башлаган. Көнгә берничә мәртәбә килгән чаклары да күп булган аның. Һаман теге малайны таләп итә икән. Ул инде тегермәнчене куркыта башлаган, бирмәсә, малайны урлап китәчәген дә әйткән.

– Нишләтмәкче буласың син аны? – дип сорарга мәҗбүр булган тегермәнче.

– Берни дә эшләтмим, балам урынына йөрер, – дигән Су анасы.

Бик озак сатулашканнан соң, тегермәнче хезмәтче малайны биреп җибәрә. Шул көннән су тегермәне торган буа җил-давылдан тына, ашлык тартырга килүчеләр дә күбәя. Тик тегермәнче генә кәефсез йөри, ятим баланы түбән рухлар карамагына биреп җибәргәне өчен җаны өзелә аның... Ул тәмам картаеп, бөкрегә кала. Ярты капчык ашлык та күтәрә алмый башлый. Менә аның бу дөньяда соңгы көне якынлаша. Ялгызы гына үләргә әзерләнә, буасы, тегермәне белән хушлашу өчен яр буена килә. Шулвакыт су төбеннән ике гүзәл зат килеп чыга. Аларның берсе – ул кайчандыр Су анасына биреп җибәргән хезмәтче малай икән. Икенчесе – Су анасының чибәр кызы, имеш. Аягында чак кына басып торган тегермәнче егетнең каршына тезләнә:

– Гафу ит мине, балам, мин синең алда бик гаепле, кичермәсәң, миңа үлү бик кыен булачак, зинһар, гафу ит, – ди ул.

Егет, кичерүен белдереп, башын ия.

Шунда тегермәнче җан тәслим кыла.

Тегермәнчене җирләгәч, егет аның урынына хезмәткә баса – кешеләрнең ашлыгын тартып, гомер кичерә башлый. Барысы да кешеләрчә була аның, тик хатынын, балаларын гына кешеләргә күрсәтми тота икән ул. Кешеләрнең моңа исләре китмәгән. Су анасы нәселеннән хатын алып кайтканын белмәгәннәр шул алар аның. Әллә... белгәнгә күрә дәшмәгәннәрме? Бу хакта әкиятләрдә бер хәбәр дә юк.

ГАИЛӘ *йолаларын* САКЛАУ

Эльвина ГАЛИМОВА,
Казан дәүләт мәдәният институтының 4нче курс студенты

2024
ГОД СЕМЬИ

Гаилә гореф-гадәтләре һәм традицияләре татар мәдәниятенең мөһим өлеше булып тора. Актив шәһәрләшү барган бүгенге заман шартларында авыл мәдәният учреждениеләрендә гаилә йолаларын саклау һәм кабат торгызу мәсьәләләрен өйрәнү аерым бер актуальлеккә ия.

«КОДАЛАР АЛУ/КОДАЛАР АЛДЫРУ», «КОДАЛАР ЧАКЫРУ» ДИП АТАЛА ТОРГАН БУ ЙОЛА АЛГА ТАБА ҮЗАРА АРАЛАШУНЫ, ҺӘР ИКЕ ЯК ТУГАННАР АРАСЫНДА ҖЫЛЫ МӨНӘСӘБӘТЛӘР УРНАШТЫРУНЫ КҮЗДӘ ТОТА

Гаиләдә бала туу, туй йолалары, яшьләрнең балигъ булу, никахлашу кебек башка статуска күчүен билгеләп үтә торган гореф-гадәтләр иң киң таралган ритуаллар булып санала. Аларны саклауда мәктәп, клуб, мәчет кебек авыл социаль институтлары әһәмиятле роль уйный.

Фәнни тикшеренүче Р.Н. Мусина фикеренчә, совет заманында һәм аннан соңгы чорда күп этаптан торган һәм һәр җирлекнең үз традицияләре булган татар туена бүген бердәйләшү һәм туй йолалары элементларын киметү хас. Шулай да шәһәр мохитендә актуальлеген югалткан күп кенә милли традицияләр авыл җирлегендә һаман да саклана әле. Кәләшкә су юлын күрсәтү, аның бирнәсеннән өй киендерү, килен токмачы хәзерләү шундыйларга керә. Ә яңа өйләнешүчеләрне чәк-чәк, бал-май белән каршы алу, кәләшнең аяк астына мендәр салу, имин гаилә тормышы теләү кебек ритуаллар авылларда гына түгел, шәһәрләрдә дә сакланып калган. Бу йолалар бүген дә яшьләр арасында зур популярлыкка ия.

Ютазы районы Иске Каразирек авылы Мәдәният йортында оешкан «Халык җәүһәрләре» фольклор коллективы, туй йолаларын үткәрү үзенчәлекләрен яңартып, «Кодаларны каршу алу» күренешен бик оста итеп башкара.

Галимә З.М. Брусько фикеренчә, «кодалар алу/кодалар алдыру», «кодалар чакыру» дип атала торган бу йола алга таба үзара

аралашуны, һәр ике як туганнар арасында җылы мөнәсәбәтләр урнаштыруны күздә тота. Кунакка килгәч, туганлык бәйләнешләрен урнаштыру һәм ныгыту өчен алар бер-берсе белән бүләкләр алмашалар. Бу йола бүгенге көнгә кадәр татарлар арасында гаять популяр санала. Ул символик мәгънәгә ия: яшь парларның никахка керүенә хәзерлек һәм ике гаилә берләшүенең рәсми башлангычы.

Чирмешән районы Түбән Каменка авылы Мәдәният йортының «Ак калфак» фольклор коллективы үзенең репертуарына яңа өйләнешүче парларның кияү йортына кайтуын – «Килен төшерү йоласы»н керткән. Ул туй йоласының матур, тәэсирләндергеч, истә калырлык этабы белән таныштыра. Бу – күптән көтелгән мизгел – кияү туганнарының күбесе моңа кадәр кәләшне күрмәгән була әле. Яшьләрне һәм кунакларны тантаналы төстә икмәк һәм бал-май белән каршылыйлар, бу «бал кебек татлы, май кебек ипле булыгыз» дигәнне аңлата. Кияүнең әнисе булачак килененең аяк астына мендәр сала – бу йорттагы муллыкны, иминлекне белдерә. Аннан соң кәләшнең бирнәсен алып керәләр. Болардан соң «Су юлы күрсәтү» йоласы башкарыла. Кунаклар, җырлап-биеп, кәләшне су юлын күрсәтергә алып китәләр. Көянтә-чиләк аскан кәләш суны түкмичә алып кайтырга тиеш, юкса, муллык булмаячак, дигән ышану яши.

Аннары кунаклар аңа зур булмаган бүләкләр тапшыра, бу – аның эшчән һәм хуҗалыкчыл булуын теләү йоласы.

Шулай итеп, авыл мәдәният учреждениеләрендә гаилә-көнкүреш йолаларын бик актив популярлаштыралар, аларны мәдәни чараларда, конкурсларда, фестивальләрдә яңарталар.

Алсу Быкова һәм Ильвира Идрисова фоторәсемнәре

«Кушкапка» бәйрәме

Лилия ҖАМАЛИЕВА,
Апас, Урта Балтай Мәдәният йорты җитәкчесе

«Кәгазь башмаклылар» – Апас районы Урта Балтай авылы халкына элек-электән тагылган, аларның мәдәниятле булуын раслаучы кушамат. Ә тарихына килгәндә болай: балтайлылар кеше арасына чыкканда, бәйрәмнәрдә чабата кимәгәннәр. Аның урынына сарык карынын эшкәртеп аяк киемнәре теккәннәр. Алар бик җайлы булган, ләкин су тисә кәгазь кебек җебегәннәр. Әлеге аяк киемен кигән Урта Балтай халкына «кәгазь башмаклылар» кушаматы да шуннан ябышып калган.

Апас төбәгендәге «кәгазь башмаклылар» яшәгән җирлектә – Түбән һәм Урта Балтай авыллары тирәсендә болынлык, күл заманында Каратун авылында яшәгән алпавыт карамагында була. Анда керү өчен капканы Каратун ягында ясыйлар. Ул «морза капкасы» дип атала. Алпавыт көчеп киткәндә болынлыкны Каратунга сатып калдыра. Түбән Балтай авылы халкы моңа каршы чыга, эше судка кадәр барып җитә. Нәтиҗәдә, карар Түбән Балтайлылар файдасына чыгарыла. Һәм авыл халкы морза капкасыннан йөрергә теләмичә, үз капкасын ясап куя. Янәшә торган ике капка «Кушкапка» исеме белән тарихка кереп кала.

Бу болынлык-җирләр Балтайга калгач, ике авылның да яшь егетләре, кызлары бергә күңел ачу бәйрәмнәре оештыра башлый. Бәйрәмгә «Кушкапка җыены» дип исем бирәләр. Әлеге җыен-бәйрәм Бөек Ватан сугышы башлангач туктала. Авылның әби-бабайлары андагы җырлы-биюле уеннарны, күңел ачуларны бүгенгәчә сагынып сөйлиләр.

«Кушкапка» бәйрәмен уздыру вакытын халык табигать күренешләре аша билгеләгән, ягъни ул июнь урталарында Сабан туе алдыннан үткәрелгән. Бәйрәмгә тирә-як авыл халкы да килгән. Уздыру урыны итеп, Урта Балтай белән Түбән Балтай авыллары арасындагы болынлык сайланган. Борынгыларның: «Кушкапкага яңгыр төшмәсә, халыкның иңе төшә» әйтеме безнең көннәргә кадәр килеп җиткән.

Авыл халкы һәрчак җыр-моңга гашыйк булган. «Кушкапка» бәйрәме алдыннан яшьләр өчен аерым уеннар оештырылган, аны «Кече Кушкапка» дип атаганнар. Сәүдәгәрләр бәйрәмгә дип, капчыклап, әстерхан чикләвеге, кипкән балык, кызыл билле ак перәннекләр алып кайтканнар. Чирү авылы халкы үзләренә генә хас булган гәрәчийләрен пешереп торганнар (майда пешергән калын коймак). Кәмитләре әйләнеп торган («кәмит» дип карусельне атаганнар). Мондый кәмиткә халык акчасын алдан ук әзерләп куйган, ел буе җыеп барган. Тирә-якта барабаннар кагып торганнар, халык кәефен шулай күтәргәннәр. Бәйрәм башында «Кушкапка» буласы урынны кыңгыраулы атлар белән әйләнеп чыкканнар. Урта Балтай белән Түбән Балтай авыллары үзләренең «Кушкапка» бәйрәме белән тирә-якта дан тоткан.

Соңгы елларда онытыла барган йолалар, гореф-гадәтләр кабаттан торгызыла башлады. Мәсәлән, 2021 елда, Буа регионында, тирә-як районнарны да кереп, борынгы утарлар мәдәниятен күтәргән зур фестиваль узды. Россиянең бик күп төбәкләреннән, чит илләрдән мәртәбәле кунаклар килде. Биредә күрсәтелгән «Кушкапка» бәйрәме кунаклар күңелендә матур тәэсирләр калдырды.

БОРЫНГЫЛАРНЫҢ: «КУШКАПКАГА ЯҢГЫР ТӨШМӘСӘ, ХАЛЫКНЫҢ ИҢЕ ТӨШӘ» ӘЙТЕМЕ БЕЗНЕҢ КӨННӘРГӘ КАДӘР КИЛЕП ҖИТКӘН.

2022 елда, районда узган «Иң яхшы мәдәният мөдире» конкурсында «Кушкапка» бәйрәме белән уңышлар яулады.

Апас якташлык җәмгыяте оешуга 30 ел тулу уңаеннан Казан шәһәрендә уздырылган юбилей кичәсендә, Урта Балтай мәктәбе укытучылары «Кушкапка» бәйрәмен күрсәтте.

Максатыбыз – милли мирасны саклау. Гореф-гадәтләрен, йолаларын, туган телен саклаган авылларның киләчәге бар. Без ул мирасны киләчәк буыннарга тапшырырга, алар, үз чиратында, үзләреннән соң килгән буынга калдырырга тиеш.

Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан

«Яңгыр теләү» йоласы

Айгөл ФАЗЫЛҖАНОВА,
Әтнә районы, Р. Бикчәнтәев исемендәге Түбән Бәрәскә Мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе

Яңгыр теләү – гасырдан гасырга, буыннан-буынга, әби-бабалардан әти-әниләргә, әти-әниләрдән балаларга һәм, күпмедер дәрәҗәдә үзгәреп, безнең көннәргә дә килеп җиткән татар халык йоласы. Ул берише район-авылларда югалып бетсә дә, күп җирлектә бүгенге көнгәчә сакланган һәм бик матур итеп үткәрелә.

Йоланы ирләр дә, хатыннар да, картлар һәм бала-чагалар да башлап йөрергә мөмкин. Ул аеруча корылык елларында актуаль. Аның максаты – Аллаһтан яңгыр сорау. Яңгыр яумаган елларда, җирләр ярылып, үләннәр саргая башлагач, авыл картлары яланга чыгып, «Яңгыр теләү» йоласын башкара: догалар укыла, табигать турында табышмаклар, сынамышлар әйтелә. Балалар йорттан-йортка кереп тәм-томнар, төрле ярмалар җыялар, таудан йомырка тәгәрәтеп уйныйлар. Өлкәннәр йомырка пешереп, тәм-томнар белән балаларны сыйлыйлар, чишмә суыннан чәй кайнаталар, тау башында, яки су буенда казан асып, ярмадан ботка пешерәләр. Ботка пешкәндә такмаклар әйтәләр.

Яңгыр яу, яңгыр яу!
Без сорыйбыз Ходайдан,
Арыштан, бодайдан,
Пәрәмәчтән, күмәчтән.
Сыерларның сөтләре
Аз булмасын, күп булсын.
Игеннәрнең башлары
Ач булмасын, тук булсын.
Яңгыр яу, яу, яу!

Пешкән ботканы тәмләп ашаганнан соң, буа янында «су сибеш» уены башлана. Шулвакыт, көтмәгәндә авыл өстендә кап-кара болыт пәйда булып, коеп яңгыр явып китә, авыл халкы, шатланышып, өйләренә таралыша.

ШУШЫ ЙОЛАДАН СОҢ БАРЛЫК АВЫЛ ХАЛКЫ ДА ЯҢГЫР ЯВУЫНА ҺӘМ, НӘТИҖӘДӘ, МУЛ УҢЫШ ҖЫЕП АЛУЛАРЫНА ЫШАНА

Шушы йоладан соң барлык авыл халкы да яңгыр явуына һәм, нәтиҗәдә, мул уңыш җыеп алуларына ышана. Эшкә дәрт өстәлә. Хәзер дә корылык елларында Аллаһы Тәгаләдән өметебезне өзмибез. Безне ишетеп, үзенең хәерле, шифалы яңгырларын бирсен иде, дип телибез.

Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан

«Печән өмәсе» йоласы

Раушания ЗАРИПОВА,
Башкортостан, Туймазы районы,
Төмәнәк Мәдәният йорты
җитәкчесе

2023 елда Башкортостан Республикасы тарафыннан үткәрелгән «Кушнаренко таңнары» фольклор фестивалендә Төмәнәк авылы Мәдәният йорты каршында эшләп килүче «Төмәнәк» татар халык фольклор ансамбле «Печән өмәсе» йоласын сәхнәләштереп, 22 район арасында 1 нче дәрәҗәле лауреат дипломына лаек булды.

Бу йолада печән чабу – безнең ата-бабаларыбызның авыр хезмәте чагыла. Әлбәттә, бүгенге көндә кул белән печән чабу – халкыбызның мәдәни байлыгына әйләнде, чөнки технологияләр камилләшкән, кул хезмәтен машиналар алыштырган чорда яшибез.

Печән чабу вакытны ала һәм көч таләп итә торган авыр хезмәт булуга карамастан, ул халкыбызны үзара бердәмләштергән. Без бу күренешне «Зиләйлүк», «Иделләре-күлләре», «Рамбар юллары», «Баламишкин», «Әйе шул, шулай шул», «Яшьлек» кебек татар халык җырлары, кара-каршы биюләр, такмаклар белән бизәдек. Әлбәттә, әзерлекне авылыбызның өлкән кешеләре белән дә киңәшләшүдән башладык.

– Без кечкенә вакытта печән чабу – җәйге иң мөһим эшләрнең берсе иде. Җирләрне

АВЫЛ КЕШЕСЕ ӨЧЕН ПЕЧӘН ӨСТЕ – ҖАВАПЛЫ ЧОР, ЧӨНКИ МАЛ-ТУАР ӨЧЕН ЕЛЛЫК РИЗЫК ӘЗЕРЛӘРГӘ КИРӘК.

бүлгәннән соң, халык печәнлеккә китә. Җирләре күбрәк булган кешеләр гаиләләре белән йөриләр, казан асып, аш-суны да болынлыкта пешерәләр иде. Печән әзерләү авыр булуга карамастан, өмә белән эшләгәч, күңелле була торган иде, – дип искә ала авылыбызның иң өлкән кешесе Саймә апа Гарданова.

Авыл кешесе өчен печән өсте – җаваплы чор, чөнки мал-туар өчен еллык ризык әзерләргә кирәк. Печәнне чабу һәм киптереп җыю өчен иң кулай, яхшы вакыт – җәй уртасы. Әби-бабайларыбыз сөйләве буенча, печән җыярга болынга бару үзе бер бәйрәм булган. Зур арбаларга («фурман» дип аталган) атлар җигеп, гармун көенә җырлар җырлап, күңелле итеп барганнар. Иң беренче эш итеп, авыл мулласы Коръән аятьләре укыган, «Эш тиз барсын, һава шартлары уңайлы булсын», – дип теләк теләп, дога кылган.

Печән чабу – бик озак һәм күп көч таләп итә торган эш булгач, ул кояш чыгуга башланып, кичкә кадәр дәвам иткән. Ир-атлар үлән чапкан, ә хатын-кызлар кипкән печәнне тырма белән җыеп барганнар. Эссе һәм коры һава торышы аеруча шатлык китергән. Печәнне җыйганнан соң, күп санлы рәтләр белән кубәләп куеп, алар үз чиратында кибәнгә өелгән. Иртән, чык төшкәннән

соң, өелгән печәнне тагын кибәргә таратканнар. Үләнне икенче тапкыр киптергәннән соң, аны яңадан кибән итеп өйгәннәр. Һава торышы яңгырлы булса, әлбәттә мәшәкать сизелерлек арткан. Әгәр дә офыкта болыт барлыкка килсә, таралып яткан хуш исле печәнне шунда ук кибәнгә җыйганнар. Яңгыр беткәч, аны таратып, печәнне яңадан киптергәннәр. Печән өюнең үз тәртибе булган. Авылдашлар арасындагы аксакаллар, печән салган сәнәкне каплап өяргә кушканнар. Бабайларның иң осталары чалгы кайрап, чүкеп торганнар. Чөнки чалгы чүкү зур осталык таләп иткән. Авылда андый осталар санаулы гына булган.

Күмәкләшеп эшләгәннән соң, ашау да тәмле булган. Ашларны махсус казаннарда пешергәннәр. Пешекче итеп, иң оста аш пешерүчене билгеләгәннәр. Һәм ул өлкәнрәк яшьтәге Акъәби булган. Өмәләргә, гадәттә, сарык чалганнар. Өмә ашын авыз итәргә бөтен авылның бала-чагасы җыела торган булган. Итле аш шулпасыннан бөтен болынга хуш ис тарган. Төшке аштан соң өлкәннәр ял иткән, яшьләр җиләк, мәтрүшкә җыйганнар, мунча өчен каен себеркесе әзерләгәннәр. Җәйге эсседә арыган халык, эштән соң, елгада яки күлдә су коенган, чәчәк һәм яңа чабылган үлән исләрен ләззәтләнеп сулаган.

ПЕЧӘН ӘЗЕРЛӘҮ ӨМӘСЕН ЯШЬЛӘР САГЫНЫП КӨТЕП АЛГАН. ЯШЬ КЫЗЛАР МАТУР КИЕМНӘРЕН КИЕП, ЕГЕТЛӘРГӘ ҮЗЛӘРЕНЕҢ УҢГАНЛЫКЛАРЫН КҮРСӘТКӘН.

Печән әзерләү өмәсен яшьләр сагынып көтеп алган. Яшь кызлар матур киемнәрен киеп, егетләргә үзләренең уңганлыкларын күрсәткән. Ә егетләр исә эш барышында үзләренә кәләш күзләгән.

Өмәләр, әлбәттә, җырсыз, уен-көлкесез үтмәгән. Яшь җилкенчәк шаярып-көлеп, ярышып, күңел ачып эшләгән. Халкыбызның халык җырлары, тәртмәле такмаклары дисеңме, берсе дә калмаган. Яшь егетләр һәм кызлар җырлый-җырлый печәнне әйләндергәннәр, өйгәннәр.

Кич белән эш беткәч, кичке уен оештырганнар. Анда да тальян гармун тавышлары тынып тормаган: уеннар уйнаганнар, җырлаганнар, кара-каршы, өчле, дүртле, бишле биюләрен биегәннәр. Яшьләр бер-берсенә булган мәхәббәт хисләрен белдергәннәр. Кайтып йөрергә ерак булганга, печәнне урламасыннар дип саклап төнгелеккә калучылар да булган. Их, ул саф һавада, яңа чабылган печән кибәннәре өстендә төн кунулары!

Бүгенге көндә ул мәшәкатьле дә, әмма кызыклы да чор турында китаплардан укырга яки фольклор спектакльләрдә генә күрергә мөмкин.

Автор фоторәсемнәре

«МИШӘРЛӘРЕМ...»

Әлки ягы талантларга бай төбәк! Сулары шифалы, һавасы тылсымлы булган безнең Әлки төбәгеннән Галия Булатова, Әзәл Яһүдин, Исламия Мәхмүтова, Рузия Мотыйгуллина, Әсхәт Хисмәтов, Әнәс Галиуллин, Фәнис Кәлимуллин, Мирсәет Сөнгатуллин, Резеда Төхвәтуллина, Нәби Дәүли, Бикә Рәхимова, Салих Маннапов, Шамил Маннапов кебек танылган артистлар, язучылар чыккан. Беренче татар фотографы Кыйвам Зөлфокаров, Рудольф Нуриевның әнисе Фәридә ханым да Әлки төбәгендә туган. Әлбәттә без, әлкилеләр үзебезнең бөек якташларыбыз белән чиксез горурланабыз, аларның иҗатларын хөрмәтлибез. Инде бакыйлыкка күчкән якташларыбызның истәлек кичәләрен һәрдаим үткәреп, яшь буынны аларның иҗатлары белән таныштырып торабыз.

Әлки төбәгендә мишәр диалекты белән, үзенчәлекле сөйләм телле татар халкы яши. Әмма еллар үткән саен сөйләм теле дә үзгәрә, югала бара. Элеккеге мишәр биюләрен, җырларын, такмакларын саклап калу йөзеннән, 2010 елда Әлки районы Мәдәният йорты каршында «Әлки мишәрләре» фольклор ансамбле оештырдык (җитәкчесе Ринас Шиһапов, мишәр биюләрен сәхнәгә куючы хореограф Любовь Борисова). Әлеге коллективның яшәвенә, репертуарының баетылуына мәдәният хезмәткәрләре дә зур

өлеш кертте. Чөнки алар, 2010 елдан бирле, районыбызда яшәүче өлкән кешеләрдән безнең төбәктә генә җырлана торган җырлардан, такмаклардан, биюләрдән торган видеокартотека булдырды. Шул мирасны саклап, өйрәнеп, халыкка җиткерүче – «Әлки мишәрләре» коллективы.

Ансамбль районда үткән барлык мәдәни чараларның, район һәм Россия төбәкләрендә узган Сабантуйларның йөзек кашы булып тора. Коллективның «иҗат сандыгында» әби-бабаларыбыздан сакланып калган изүләр, чулпылар, калфаклар, чигүле читекләр саклана. Шуларны киеп башкарылган җыр-биюләр тамашачыда тагын да зур кызыксыну уята. «Әлки мишәрләре» ансамбленең һәрбер авыл мәдәният йортында диярлек дәвамчылары бар. Коллектив башкарган җыр-биюләрне авыл клублары каршында эшләп килүче сәнгать түгәрәкләренә йөрүче балалар да өйрәнә һәм куллана. Димәк, әлеге биюле җырларның киләчәге дәвамлы.

«Әлки мишәрләре» фольклор коллективы авыр хәлдә калган гаиләләргә, яман чир белән авыручыларга ярдәм йөзеннән бик күп хәйрия концертлары да оештыра. Әле күптән түгел генә алар Мәскәү шәһәрендә узган танылган эстрада йолдызы Дмитрий Маликов тарафыннан оештырылган «Время делать добро» исемле акциядә «Әлки якташлык җәмгыяте» белән берлектә катнаштылар. Әлбәттә, әлеге кичәдә «Әлки мишәрләре»нең дәртле җырлары яңгырады, матур костюмнары да тамашачыны битараф калдырмады.

Халык мәкале, «Үткәнен белмәгәннең, киләчәге юк», ди. «Әлки мишәрләре» фольклор коллективы үзенең элеккеге җырларын белә, өстәвенә, киләчәккә – яшь буынга тапшырып калдырырга тырыша. Алар якташыбыз Шамил Маннапов әйткәнчә:

Туган ягым төсе –
мишәрләрем,
Туры әйтеп янган исәрләрем,
Наныйларым, канәт,
әзиләрем...
Туган ягым төсле
мишәрләрем,
Күңелемдә һәрчак исәннәрем
Каты телле йомшак
күңелләрем,
Сезнең белән үтсен
гомерләрем,
Әй канәтем, наныйларым,
әзиләрем –
Мишәрләрем!

Рәсимә ГАЙФУЛЛИНА,
Әлки районы мәдәният бүлеге җитәкчесе

Автор фоторәсемнәре

ТЕАТР СӘНГАТЕН *ярат учылар*

1976 ел. Авылдашыбыз Минзада апа Гәрәева (1926-2018), яшьләрне җыеп, спектакльләр куя башлый. Алар тамашачылар күңеленә хуш килә, яңа пьесалар куярга дәртләндерә.

1981 елдан сәнгать сөючеләрдән торган үзешчән коллективны Чаллы Башы Мәдәният йорты җитәкчесе Илсөяр Дәүләтшина җитәкли. Шул еллар эчендә күп кенә пьесалар сәхнәләштерелә, спектакльләрдә күбесенчә авыл тормышы, халыкның көн күреше чагыла. Моңа мисал булып, «Яшел эшләпә» (Г. Насрый); «Кондырлы кодачасы», «Оҗмах ишеге төбендә», «Әхти, егетләр» (Ф. Садриев); «Сафура бураннары», «Өти балак» (Ю. Әминов); «Гөргери кияүләре», «Без бит авыл малае» (Т. Миңнуллин); «Кичер мине әнкәй» (Р. Батулла); «Сине ташлап китә алмыйм» (С. Шәкүров); «Мөгезле Мәүлихан» (Д. Салихов); «Су төбендә сөйгәнем» (З. Хәким); «Тәүбә йорты» (Р. Сәетгәрәева) пьесалары тора.

2004 елның гыйнварында «Заман» коллективына «халык театры» исеме бирелә. Коллектив Норлат шәһәрендә З. Хәкимнең «Килә ява, килә ява»,

Чистай шәһәрендә М. Мәсифуллинның «Тискәре ир, начар хатыннар» спектакле белән зона ярышларында катнаша. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Республика халык иҗаты һәм мәдәни-агарту эшләре фәннигетодик үзәге оештырган халык театрлары декадасында чыгыш ясап, III дәрәҗә дипломга ия була.

«Туй күлмәгем – соңгы бүләгем» (Д. Салихов), «Безнең авылның кызлары» (Ф. Садриев) – «Заман» халык театрының аеруча уңышлы спектакльләре. «Безнең авылның кызлары» спектакле 2015 елда «Идел-йорт» фестивалендә II дәрәҗә лауреат исемен яулый.

2004 елда «Заман» халык театры каршында «Өмет» балалар театры да оештырыла. Алар да үзләренең остазларыннан үрнәк алып, уңышлы чыгышлары белән сөендереп торалар: 2013 елда Т. Миңнуллинның «Гашыйк буласым килә» пьесасын сәхнәләштереп, II дәрәҗә лауреат исеме алалар. 2015 елда Р. Сәгъдинең «Алсу томан» пьесасын куеп, «Иделкәем» балалар-яшүсмерләр театр һәм курчак коллективлары республика конкурсында дипломант булалар. «НеСтоЛица» республика балалар-яшүсмерләр театраль фестиваль-конкурсында II дәрәҗә дипломант һәм «Традицияләргә тугрылык өчен» дипломы белән бүләкләнәләр.

2023 елда Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Өмет» балалар театрының өметле булуын раслап, үзләренә «Үрнәк балалар театры» исеме тапшырды.

Эшебезнең нәтиҗәсе булу бер сөендерсә, үз тамашачыларыбыз булу икеләтә шатлык. Чөнки Яңа Чишмә районы Чаллы Башы авылында театр сәнгатен яратучы халык яши. Киләчәктә дә эшебез дәвамлы булсын, театрыбызга халык яратып йөрсен, иҗат чишмәбез ургып аксын иде.

Гөлнара СӘЛАХОВА,
«Заман» халык театры режиссеры.
Яңа Чишмә,
Чаллы Башы авылы

Автор фоторәсемнәре

Дүртенче томда – тылсымлы әкиятләр



Татар халык иҗаты: 25 томда. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2021 – 4 т.: Әкиятләр (Тылсымлы әкиятләр) / [төз., текст, иск. һәм аңл. әзерл. И.Г. Закирова]. – 2023. – 438 б.

Фольклористика фәне ике канатлы: аның берсе моңа кадәр тупланган халык авыз иҗаты әсәрләрен өйрәнү белән бәйле зур юнәлешне тәшкил итә, ә икенчесе халыктан фольклор үрнәкләрен җыю-туплау белән бәйле. Татарлар яши торган төрле төбәкләргә махсус чыгып, җирле халыкның рухи һәм матди мирасын барлау, аны фәнни нигездә өйрәнеп, кабат җәмәгатьчелеккә җиткерү – фольклористиканың гына түгел, гомумән, фундаменталь фән белән шөгыльләнә торган академик оешмалар эшчәнлегенең дә зур бер тармагы.

XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында Татарстан Фәннәр академиясенең системалы эшчәнлеге нәтиҗәсендә татар халык авыз иҗатын академик дәрәҗәдә барлау һәм өйрәнү эше яңа баскычка күтәрелә. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан уздырылган комплекслы фәнни экспедицияләрдә фольклорчы галимнәр эшчәнлеге аерым бер юнәлеш рәвешен ала. Соңгы елларда, экспедициядә җыелган материалларны тикшерү, анализлау, фәнни әйләнешкә кертү белән бергә, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивында 1940 еллардан башлап туплана килгән мирасны барлау, яңа кайткан мәгълүматлар белән чагыштыру эше дә башкарыла, шул җирлектә күпсанлы яңа фәнни хезмәтләр әзерләнә.

«Татар халык иҗаты»ның 25 томлыгы – шундыйларның берсе. Күптомлык моңа кадәр дөнья күргән унөчтомлык академик басмага кергән материалларны да, аларга керми калган кайбер үрнәкләрне дә һәм академик томнар чыкканнан соң табылган фольклор җәүһәрләрен дә игътибар үзәгенә алуны күздә тота. Бу эшнең максаты – халыкның рухи байлыгын үзенә кайтару, аны популярлаштыру, тарихка кертеп калдыру, фольклордагы күп гасырлык табышларны бербөтен итеп күзаллап, күпьеллык фәнни-тикшеренү нәтиҗәләрен гомумиләштерү. 25 томлык татар халык иҗатының төрле жанрларына караган әсәрләрне үз эченә алган аерым китаплардан «Татар мифологиясе», «Йола иҗаты», «Әкиятләр» (6 китапта), «Дастаннар», «Китаби дастаннар», «Табышмаклар», «Мәкальләр һәм әйтемнәр» (2 китапта), «Мәзәкләр» (2 китапта), «Бәетләр» (2 китапта), «Мөнәҗәтләр», «Риваятьләр һәм легендалар», «Җырлар» (4 китапта), «Балалар фольклоры» (2 китапта) тора.

Татар халык әкиятләре академик 25 томлык «Татар халык иҗаты»ның алты китабында урын алган. Басмасының дүртенче томына татар халкының тылсымлы әкиятләре тупланган.

УКЫГАН БАЛА

Йортта бер мулла бар икән, бу мулла балаларны укыта икән. Ун бала икән укыта торган. Бер кеше тагын бер бала алып бирде укытырга. Мулла әйтә инде:

– Өч ел балаңны укытам! Һөнәргә өйрәтәм! Өч елдан танып алсаң, ал балаңны, танып алмасаң, минеке булсын! – диде. Баланы калдырып китте бу кеше. Бала мулланың өендә калды. Бер ел укыды, ике ел укыды, өч ел укыды. Һөнәргә өйрәнде, мулласыннан артык булды.

Вакыт инде җитте. Бала төндә, чебен булып, тәрәзәдән чыгып китте, атасының өенә очып китте. Атасына әйтте:

– Әй ата, вакыт җитте мине алырга. Таң белән син муллага бар, мине ал! Барсаң, мине танырсыңмы? Танып алсаң алырсың, танымасаң, мулла мине алып калыр. Без унбербез. Безне, унбер кош кылып, мулла идәнгә җибәрер. Син барыр булсаң, безне күрерсең. Мине кайдан белерсең? Мин канатымны сугармын, минем балам, дип әйтерсең муллага, – диде.

Бала очып кайтып өенә килеп ятты. Иртән торды, бала муллага әйтте:

– Минем атам бүген алырга килә.

Мулла әйтте:

– Сүзең рас, – диде. Унбер баланы унбер кош кылып куйды, бары бер шикелле кош булды. Бер вакыттан соң баланың атасы килде, муллага әйтте:

– Әй муллам, баламны алырга килдем.

Мулла:

– Ярар, – диде. – Бу монда унбер кош шәкертләрем, алардан балаңны танып ал. Күр! Балаңны танысаң синеке, танымасаң минеке! – диде. Килеп иңеп карады атасы, карап торды, кайсыберен белмәде, берәү канатын килеп сукты.

– Минем балам бу икән, – дип ушлады канатын суккан кошны. Мулла көлде, әйтте:

– Танымас идең балаңны, белдерде балаң, берең таптың.

Атасын чыгарды, мулла унбер кошны алды, ул унбер коштан унбер егет кылды, берен бере шикелле кылып куйды. Атасын чакырып иңгезде. Атасы карады, кайсы берен белмәде, бер егет утырып бармак белән авызына какты. Атасы:

– Минем балам бу икән, – дип, бу егетне тотты. Мулла әйтте:

– Ал инде балаңны!

Баласын бу кеше алып китте. Өендә бер өч көн ятты. Бала әйтте атасына:

– Әй әкә, мине ат кылып сат! Мин ат булам.

Ат булды баягы бала. Атасы өстенә менеп алып чыкты. Бер кеше килеп сөйләште:

– Синең атың яхшы икән, – диде, – сатамысың?

Баягы кеше:

– Сатамын, – диде.

– Канча[1] сорыйсың? – диде.

– Йөз тәңкә бирсәң ал!

Караса, баягы баланың атасы, мулла килеп утырыр.

– Атың миңа сат! – диде, – мин артык бирәм.

Мулла йөз егерме тәңкә бирде, атын алды. Мулла атны менеп алып китте.

Мулла, өйгә килеп, бу атны бер туюк[2] сарайга бикләде. Ат булган бала кош булып, бер тишек табып, тишектән чыгып китте. Мулла, аны белеп, соңыннан кош булып куды. Инде җитәм дигән чакта, бала түбән төшеп суга иңде, балык булып су астында йөрде. Мулла һәм балык булып суга төшеп йөрде куып. Мулла чуртан булып җитеп йотарга булды, баягы егет түбәндәге бер тишеккә керде, мулла, чуртан булып барып, башын тишеккә тыкты, йотасы булды. Юрыш[3] булган баланы йоталмады. Мулла тишектән чыгып кайтып килде, бу егет тә чыгып очты кош булып.

Барып, бер ханның ишегалдына кунды. Ханның бер итәнче[4] кызы бар икән. Ул кыз өйдән чыгып чүп түкте. Бер кошны күрде. Итәнче кыз бу кошны тотты, өйгә алып иңгезде. Өйнең эчендә бер җирдә кундырды. Ханның кызы бар икән. Ханның кызы бу кошны күрде. Әлеге кош бер егет булды. Кыз әйтте:

– Син ни егетсең? – диде.

Егет әйтте:

---
[1] Канча – күпме.
[2] Туюк – бикле, йозаклы.
[3] Юрыш – ёрш, балык.
[4] Итәнче – идән юучы.

– Мине истәп килә дигән мулла килер, син мине кулыңа алып, йөзек кылып каткын[5]! – диде. – Мулла өеңә килсә, син, кулыңны күтәреп, йөзекне аңа күрсәт. Әгәр мулла күрсә, ул сорар: ул йөзекне миңа бир, дип әйтер. Идәнгә төшеп уйна[6], йөзекне бирәм, дип әйт! – диде. – Мулла төшеп уйнар. Уйнар көч беткәнче. Аннан соң йөзекне бир инде. Алам дигән чакта тагы тартып ал!

Кыз әйтте егеткә:

– Мин сине ни кылып йөзек кылып катарым?

Егет утырды, йөзек булды да китте. Кыз бу йөзекне алып катты.

Ничә вакыт соң мулла кызның өенә иңеп килде. Кыз кулын чыганакка[7] терәп, йөзекне күрсен, дип утырды. Йөзекне мулла күрде, әйтте:

– Йөзегеңне миңа бир!

Кыз әйтте:

– Мулла, идәнгә төш, уйна!

Мулла идәнгә төште, уйнады, уйнады, бетте көче мулланың.

– Инде йөзекне бир! – диде. Кыз кулын сонды:

– Мә, ал! – диде. Кулын уйнап тагын тартып алды. Йөзек ярма булып чәчелеп китте. Мулла корас[8] булып китте, баягы ярманы чүпләде, инде. Берәү ярманың кош[9] булды, кораска килеп типте, корасның башы өзелеп китте. Аннан соң бу кош баягы корасны тышкары ташлап җибәрде. Аннан соң кош кайтара[10] егет булды. Кыз әйтте:

– Мин сиңа барам! Минем вәгъдә шулай булсын! Минем ни дигәнем булсын!

Кыз барды моңа, кызны алып, өенә күчереп китте. Өенә бардылар. Бер елда болар көн күрделәр өйдә. Хатыны бер ир бала тапты. Бала үсте, үсте, бер яшькә чыкты. Хатын өендә ут якты, хатын баланың каршында утырды. Бервакыт баланы тотып утка ташлады, бала көеп[11] китте. Егет сыктады:

– Әй, – диде. – Баламны нигә утка ташладың?

Хатыны әйтте:

– Синең эшең юк, мин синнән вәгъдә алдым.

Хатыны янә бер кыз бала тапты. Баягы кыз янә бер яшькә чыкты. Тагы хатын баланы утка ташлап җибәрде. Тагы егет сыктады. Хатыны тагы әйтте:

– Синең эшең юк, биргән вәгъдәң бар.

Бер өч ел үтте. Хатыны әйтте:

– Атам белән инәмә барыйк! Сәиллик[12]! Югалган нәрсәң анда табарсың, – диде. Ат җигеп сәилләп киттеләр. Бардылар. Атасы белән инәсе каршы чыктылар боларга. Ике мындай бала бергә йөгереп чыкты. Хатыны сорады:

– Әй ирем, бу ни бала? – диде. Ире әйтте:

– Мин белмәмен бу ни бала икәнен.

Хатын әйтте:

– Минем утка ташлаган балам бу, кой. Минем инәмне мин алганмын ут булып. Бу синең балаларны алып китте инәм.

Баласын кочаклап алды. Бер өч көн анда кундылар. Дүртенче көнне кайттылар. Урта юлда ике елан сугышып ятыр. Берәү кара, берәү ак. Икәве өлкән булды, каек шикелле. Кара елан ак еланны җиңә, ак еланның көче беткән икән. Бу егет йөгереп мылтыгын кулына алды, кара еланны атты. Кара елан үлде, ак елан бер адәм булып китте. Бу адәм әйтте:

– Әй егет, мине үлемнән коткардың. Бу кара елан минем колым иде. Мин бер ханның улы идем. Йөр, егет, минем шәһәргә бараек!

Бу кеше егетне хатыны белән, баласы белән шәһәренә алып китте. Шәһәргә җиттеләр. Ханның өенә төштеләр. Хан атасы аларны бик сыйлады. Ханның улы әйтте:

– Бу егет мине үлемнән коткарды, минем колым мине үтерергә иткән. Бу егеткә бирә дигәннән аяма[13]! Ни сораса бир!

Хан әйтте:

– Бер кызым бар, алсаң, аны бирим!

Егет әйтте:

[5] Кату – кию.
[6] Уйнау – бию.
[7] Чыганак – терсәк яки беләзек.
[8] Корас, корос – әтәч.
[9] Кош – ерткыч кош, ау кошы.
[10] Кайтара – кире.
[11] Кєю – яну.
[12] Сәил, сәйел – күңел ачу (табигатькә чыгу).
[13] Аяу – кызгану.

– Ярый! – диде. Хан туй кылды, туйлап кызын бирде. Бер табын[14] сыер бирде, бер табын ат бирде, унбиш кеше кол бирде, алтын-көмеш бирде. Егет инде куәкәле булды. Егет кучеп кайтты. Инде егет шундый бай булды, ике хатыны белән кенен курделәр анда.

БЕР КАРЧЫКНЫҢ УЛЫ

Бер карчык бар икән, аның бер улы бар икән. Бу карчыкның улы бер эт сатып алды, инәсе моны орышты:

– Эт нигә кирәк сиңа? – диде. Икенче көнне улы янә барды, бер мүшәк[15] сатып алды. Чыгып китте улы, эт белән мүшәк белән урманга китте. Барды, барды егет, күп мал үтерде, кеш мал, тиен, төлке – күп алып килде. Икенче көнне тагы китте, тагы күп мал атты. Атка малны йөкләп янә өйгә алып килде. Өченче көндә этен, мүшәген калдырды өйдә, үзе ялгыз урманга китте. Урманда үлән белән ут көеп килә иде. Утның алдында бер елан качып килә. Елан егеткә килде һәм әйтте:

– Әй, коткарчы мине, егет, бу уттан!

Егет еланны җиңенә алып салды, утны үтеп китте. Елан әйтте:

– Егет, мине өемә алып бар! Бу яткан юл белән барсаң, өемә җитәрсең.

Елан күрсәткән юл белән китте. Юлда бу елан җиргә төште, кыз булып китте.

Кыз әйтте:

– Йә егет, син мине ал! Егет әйтте:

– Юк, мин сине алмаймын.

Кыз әйтте:

– Адәм дә булабыз, елан да булабыз. Мине алып барсаң, атам сине бай кылыр, – диде. Егет кызны алып китте, күп бардылар. Егет әйтте:

– Карыным минем ачты, аш юк, – диде. Кыз әйтте:

– Тукта! Аш бирәем!

Кыз бер кечкенә таш алды, бу ташны егетнең авызына салды. Егетнең карыны да туеп китте, сусавына да булышты. Тагы барып-барып, бер вакытта атасына җиттеләр. Әлеге кыз әйтте:

– Өебезгә инде керәбез, син курыкма!

Өйгә керделәр, өйнең эчендә ике елан ятар, бере бик олы елан икән, берәве ак, берәве кара. Кыз әйтте:

– Берәве монда – атам, берәве – анам.

Бу яткан еланнар кеше булып тордылар, кызларын күрделәр. Кыз югалып киткәнгә өч ел булган.

Ата әйтте кызына:

– Кайда йөрдең, балам?

Кыз әйтте:

– Мин юл ялгыштым, бу егет мине табып алды, үлемнән мине котылдырды.

Атасы әйтте:

– Әй егетем, кызымны сиңа бирәем!

Егет әйтте:

– Бу кызны алмаймын.

Атасы әйтте:

– Кызымны алмасаң, алтын бирәем сиңа.

Атасы бу егеткә ат башыдай алтын бирде.

Егет анда бер атна ятты, аннан ары алтынны алып өйгә кайтты.

Барып, барып өенә җитте, инәсе белән күреште. Баягы егет иртән эт белән мүшәк белән урманга чыгып китте. Урманда йөреп, мал эзләде, эзләп йөреп, бер юл тапты, дүрт көн барды. Караса, агач башында мал[16] утырыр. Атты, мал җиргә төште, егет аны алды. Малның йоны көмеш шикелле, бу малны алды, өенә кайтты. Караңгы өйнең эче якты булды, шәм янган шикелле. Бу егетнең мондый мал үтергәнен патша ишетте. Патша егетне чакыртты, малын алып барсын дип әйтте. Егет бәясен сөйләшә белмәде. Патша үзе, аңа сигез йөз тәңкә биреп, малын алды. Егет акчаны алып өенә кайтты, китеп өйләнде, кызын алып, баеп, хатыны белән үз өендә торды.

[14] Табын – көтү.
[15] Мүшәк – мәче.
[16] Мал – затлы мехлы җәнлек.

«ЯҢГЫР ЧАКЫРУ» кичәсе

(Мәктәпкә хәзерлек төркеме балалары өчен җырлы-биюле музыкаль күренеш)

Розалия ШӘЙДУЛЛИНА,
Арча, «Үрнәк» балалар бакчасы музыка җитәкчесе

(Кызлар кулларына чиләкләр тотып, чишмәгә төшәләр. Чиләкләр белән бию башкаралар. Биегәч, берәрләп чишмәдән су алалар, кырыйга куя баралар. Шул арада атка утырып малайлар да килә. «Атта чабу» биюен башкаралар.)

Малайлар: Әссәламүгаләйкүм, кызлар!
Кызлар: Вәгаләйкүмәссәлам!

(«Шома бас» җырлы-биюле уенын уйныйлар.)

Кызлар:
Уйнат, уйнат гармуныңны,
Биесеннәр егетләр.
Безнең илнең егетләре
Бары да бөркет кебекләр.
Их, күңел ачабыз,
Ничек шома басабыз!
Малайлар:
Уйнат, уйнат гармуныңны,
Җилкенсеннәр яшь кызлар.
Безнең кызлар нурлы йөзле,
Әйтерсең лә йолдызлар.
Их, күңел ачабыз,
Ничек шома басабыз!
Бергә:
Уйнат, уйнат бию көен,
Ашыксыннар барысы да.
Кызлар: Яшь егетләр чакырсыннар,
Малайлар: Кызлар чыксын каршыга.
Бергә:
Их, күңел ачабыз,
Ничек шома басабыз!
Самат: Дуслар, көннәр бигрәк кызу тора.
Алия: Бу кызуда чирәмнәр дә корып бетә,
чәчәкләргә су сипмәсәң, шиңәләр.
Айзат: Басуларда да уңыш корылыктан интегә.
Адилә: Киләчәк көннәрдә яңгыр яумаса, бик
авыр булачак.
Кызу чагы көннәрнең.
Яңгыр көтә гөлләрем:
– Кил, яңгыр, яу-яу!
Яу, яңгыр, яу-яу!
Ранель:
Яңгыр көтә
Бакчабыз,
Яңгыр көтә
Барчабыз:
– Кил, яңгыр, яу-яу!
Яу, яңгыр, яу-яу!
Айзат:
Яңгыр килде,
Яңгырап,
Каршы алдык
Без, җырлап:
– Кил, яңгыр, яу-яу!
Яу, яңгыр, яу-яу!
Элина: Элекке заманнарда кешеләр «Яңгыр чакыру» йоласы үткәргәннәр.

Рәсүл: Минем әби: «Җәйге корылыктан котылырга теләп, яңгыр сорап, бер-беребезне су белән коендырып, су буенда пешкән ботканы яисә боламыкны бергә утырып ашап, калган ботканы, шәфкатьләндерү өчен, «су иясе»нә дә биреп, «Яңгыр чакыру» йоласы үткәрә, догалар укый идек», – дип сөйли.

Ранель: Бик коры җәйдә, яңгыр хөрмәтенә, корбан чалу да булган.
Яңгыркаем, яу, яу,
Кара сарык суярмын,
Ботын сиңа куярмын,
Тәти кашык бирермен...

Самат: Дуслар! Без бүген ботка пешермичә, догалар укымыйча гына, җырлап-биеп, уйнап яңгырны чакырып карыйк.

(«Яңгыр, яу!» җырын башкаралар.)

Яңгыр, яңгыр, яңгыр, яу!
Көмеш кадак, ука бау...
Яу син, яу килеп кенә,
Тыпырдап биеп кенә,
Чамасын белеп кенә,
Җиргә ямь биреп кенә.

Яңгыр, яңгыр, яңгыр, яу!
Көмеш кадак, ука бау...
Яу син, яу көмеш булып,
Өлгергән җимеш булып,
Зәңгәр чәчәкләр булып,
Ал-кызыл мәкләр булып.

Яңгыр, яңгыр, яңгыр, яу!
Көмеш кадак, ука бау...
Җиребез дымга туенсын,
Игеннәр гөрләп уңсын.
Муллык, гүзәллек иле –
Туган ил балкып торсын!

Алия: Дуслар, минем йөзегем бар, әйдәгез «Йөзек салыш» уйнап алыйк.

(«Йөзек салыш» уенын уйныйлар. Балалар тезелешеп утыра, берәү «йөзек салучы» була. Ул кулларын тотып утырган балаларның учларына «йөзек салып» чыга. Йөзекнең кемгә туры килүен берәү дә сизмәскә тиеш. Аннан соң үзе бер кырыйга китеп: «Кемдә йөзек сикереп чык», – ди. Йөзекле кеше сикереп чыкканда ике күршесенең берсе тотып кала алса, йөзекле кешегә җәза бирелә, тота алмасалар йөзек салу яңадан башлана.)

Айзат:

Яңгыр, яу, яу, яу!
Тәти кашык бирермен,
Тәмле ботка бирермен,
Тәти кашык базарда,
Майлы ботка казанда.

Самат:

Яңгыркаем, яу, яу!
Игеннәр дә күп булсын,
Сыерлар да тук булсын –
Безгә катык, сөт булсын,
Яңгыр, яу, яу, яу!

Сабина:

Яңгыр, яу, яу, яу!
Сине көтә җир, җир!
Безгә күмәч бир, бир!

Хәйдәр:

Яңгыр, яу, яу, яу!
Ипи-күмәч зур үссен,
Безгә сөенеч килсен!

Рәсүл:

Яңгыр, яу, яу, яу!
Бакчаларда алмагач
Үсми, яңгыр яумагач.
Бакчалардан ни файда,
Алма пешеп тормагач,
Яңгыр, яу, яу, яу!

Элина. Яңгырны чакырганда су белән коендырыш булган!

(Малайлар-кызлар бер-берсен су белән коендыра башлыйлар, көлешәләр.)

Адилә:

Без уйныйбыз, уйныйбыз,
Якты көннән туймыйбыз;
Кулны кулга чаба-чаба
Көләбез дә җырлыйбыз.

(«Бииләр итек, читекләр» (Мохтар Минһаҗев көе, Шәүкәт Галиев сүзләре) җырын башкаралар.)

Гармун уйныйм, гармун уйныйм,
Һаман гармун уйныйм мин,
Остарып җиткәч, барсын да
Биетергә уйлыйм мин.

Учларыңны шакылдатып,
Чәчләреңне сыпыр да,
Тыпыр-тыпыр, тыпыр-тыпыр,
Тыпыр-тыпыр тыпырда.

Әй, бии итек, читекләр!
Әй, уйныйм мин, уйныйм мин,
Минем кебек шәп гармунчы
Юктыр диеп уйлыйм мин!

Кәрим:

Бие, бие, биесәнә
Шушы такмак көенә.
Тыпыр-тыпыр бер биесәң,
Күңел генә сөенә.

(«Татар биюе»н башкаралар.)

Амира: Дуслар! Карагыз әле, болытлар куера, яңгыр яварга җыена бугай!

Балалар: Ура!

(Малайлар кызларның чиләкләрен алып, парлашып чыгалар.) ❦

Автор фоторәсемнәре

КИКИРИКҮК

Наилә Яхина көе
Рифә Рахман шигыре



Уятып безне йокыдан,
Әтәч иртән кычкыра.
Торырга вакыт җиткән дип,
Читәндә басып тора.

Кушымта:
Кикирикүк! Кикирикүк!
Уяныйк иртән иртүк!

Нурлар чәчеп, кояш чыга,
Уяна күбәләкләр.
Бер-берсенә сәлам бирә
Болындагы чәчәкләр.

Кушымта.

Уяна кырлар, урманнар,
Кош-кортлар уяналар.
Яңа көннең тууына
Алар бик куаналар.

Кушымта.

«Татарханә» проектының «Татар табыны» рубрикасыннан. Мастер-классны «Тәмле булсын» рестораннар челтәре җитәкчесе, Татар ашлары һәм мәдәнияте Халыкара ассоциациясе президенты, Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре, танылган аш-су остасы **Резидә Кыям кызы ХӨСӘЕНОВА** алып бара

«Татарханә» проекты

2022 елның 23-25 декабрендә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты һәм Татарстан Республикасы мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге белән берлектә, «Татарханә» проектын гамәлгә куйды. Әлеге проектның беренчесе 2021 елда тормышка ашырылган иде. «Татарханә» – «Татар киеме», «Татар табыны», «Татар ярышы» рубрикаларында татар халкының этномәдәни мирасын тәкъдим итүче тарихи-агарту проекты. 2022 елда «Татар табыны» рубрикасы татар халкының бөек улы, мәгърифәтче, тел галиме, язучы, тарихчы, этнограф Габделкаюм Габделнасыйр углы Насыйриның махсус хезмәте – «Наставления повару» китабына багышланды. Шушы китаптан алынган рецептлар буенча «Тәмле булсын» рестораннары челтәре җитәкчесе, Татар ашлары һәм мәдәнияте Халыкара ассоциациясе президенты, Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре Резидә Кыям кызы Хөсәенова һәм студия кунаклары «Кабак боткасы», «Яшелчә ашы», «Күркә кәбабы», «Миндальле печенье», «Чапкан кәбаб» кебек милли ризыклар буенча мастер-класслар уздырдылар.

Каюм Насыйри һәм аның ризык әзерләү тәкъдимнәре

XIX йөз – Россия тарихында гомумән, татар иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышында, аерым алганда, зур үзгәрешләр чоры буларак характерлана. Үзенең киң кырлы эшчәнлеге белән танылган, бөтен тормышын, талантын үз халкын агартуга багышлаган мәгърифәтчелек хәрәкәтенең күренекле вәкилләреннән берсе Каюм Насыйри (Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров) милли рухи тормышыбыз мәйданына шул вакытларда чыга.

Ул 1825 елның 14 (2) февралендә элекке Казан губернасы Зөя өязе Югары Шырдан (хәзерге Татарстан Республикасы Яшел Үзән районы Кече Шырдан) авылында туган. Башлангыч белемне атасыннан ала, аннары укуын Казан мәдрәсәләренең берсендә дәвам иттерә. Алга таба Казан университетында ирекле тыңлаучы сыйфатында лекцияләргә йөри.

Укуын тәмамлагач, Казандагы Духовное училищеда, Духовная семинариядә татар теле укытучысы булып эшли. Төрле елларда Казанның төрле урыннарында татар балаларына русча укыту өчен башлангыч мәктәпләр оештыра. Әйтергә кирәк, эшләре уңай гына бармый: төрле яктан һәрдаим куркытулар булып тора, хакимияткә шикаятьләр бирелә.

Мәдрәсәләрдә рус теле укытыла башлагач, К. Насыйри да бер мәдрәсәгә тәгаенләнә. Ләкин ул анда Василий Радлов (1837-1918) тәкъдим иткән укыту ысулы белән килешмичә эшеннән китә һәм 1879 елдан беркайда да рәсми хезмәттә булмыйча, иҗат эше белән шөгыльләнә башлый.

Аның хезмәтләре татар әдәбиятына, теленә, тарихына, этнографиясенә, эпиграфикасына, дәреслекләр һәм календарьлар, сүзлекләр төзүгә, математикага, географиягә, ботаникага, медицинага, ювелирлык эшләренә һәм башка өлкәләргә багышлана. Санкт-Петербургта нәшер ителгән фәнни журналларның берсендә аның «Казан татарларының тормышларына сөнни ислам тәэсиреннән тыш барлыкка килгән ышанулары һәм йолалары» дигән саллы хезмәте басылып чыга.

Каюм Насыйри музееннан

Ф.Ә. Зыязов. «Самавыр янында», 1975

Галим-мәгърифәтче, дин белгече һәм җәмәгать эшлеклесе Ризаэтдин Фәхретдин гаиләсе. Р. Фәхретдин, Нурҗамал, оныклары – Җәвид, Җәүдәт, Наилә

К. Насыйриның гыйльми эшчәнлеген югары бәһаләп, Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте аны бертавыштан үзенең хакыйкый әгъзасы итеп сайлый. Шул рәвешле, ул рәсми яктан фән кешесе буларак танылу ала.

Татар әдәбиятында дидактик жанр куллана башлауны, хыялый романнар яза башлауны һич икеләнмичә К. Насыйри исеме белән бәйләргә мөмкин.

К. Насыйриның Казан мещаны Мөхәммәтвәли Яхин белән берлектә татар телендә «Таң йолдызы» дигән газета чыгару идеясе белән дә йөргәнлеге мәгълүм.

Аның Казанда йорт-җире булмый. Төрле фатирларда яши. Соңгы тору урыны туганы Габделбәдигъ мөәзиннең өенең түбәнге каты була. Шунда 1902 елның 20 августында (2 сентябрендә) 77 яшендә ялгызлыкта вафат була. Мәрхүм Яңа Татар бистәсе зиратында дәфен кылына.

К. Насыйриның «Иршад әл-Әтбиха илә Истихзар әл-Әтгыймә» (1893) дигән хезмәте шулай ук игътибарга лаек. Анда ризык әзерләүнең 70 төрле ысулы бәян ителә. Мәсәлән, пылауның гына да 10 нан артык, компотның 4 төре китерелә. Төрле җиләк-җимешләрдән кайнатмалар, өй шартларында куас һәм сыра әзерләү буенча тәкъдимнәр зур кызыксыну уята. Шунысы игътибарга лаек: ризык составында кулланыла торган әйберләрнең күпчелеге үзебезнең җирлектә җитештерелә.

Бер ашау белән икенче ашау арасындагы вакыт озынлыгы, ашау вакыты, тәгам җыю әдәбе турында китерелгән мәгълүмат шулай ук файдалы киңәш булып исәпләнелә.

Әлеге китап 2015 елда Казанда рус телендә «Наставления повару» атамасы белән нәшер ителде.

Рәмил Исламов,
филология фәннәре докторы

(«Татарханә» проектының презентация материаллары җыентыгы ТАТАРХАНӘ / ТАТАРХАНЕ / TATARHANE Казан, 2022)

МИНДАЛЬЛЕ *печенье* *(Локмә* бадәм)*

Ярты кадак татлы бадәм ал. Бик яхшы арчы, вак итеп барысын төй, ярты кадак шикәр сал, дарчин төеп сал, өч йомырка агы сал, боларны тәмам катыштыр. Табаны җылытып майла, бу матдәңне вак итеп сал, мичкә куеп кәбаб ит.

КИРӘКЛЕ ИНГРЕДИЕНТЛАР:

250 грамм бадәм (миндаль),
3 данә йомырка,
250 грамм шикәр,
15-20 грамм төелгән дарчин (корица),
15-20 грамм үсемлек мае.

* Локмә – кечкенә кисәк ашамлык, бер кабым.

1 Миндальле печенье пешерү өчен кирәкле булган ингредиентларны алдан әзерләп куябыз. Бадәмне ваклыйбыз.

2 3 йомырка агына шикәр комы кушып, блендер белән болгатабыз.

3 Әзер массага вакланган бадәм кушабыз.

4 Аннары әзерләп куйган дарчинны салып, тагын блендер белән болгатабыз.

5 Килеп чыккан массаны кондитер капчыкка тутырып, пергамент яисә махсус кәгазь җәелгән табага, яисә җылытылган, майлы табага үзебез теләгән формада салып чыгабыз. Уртасына бадәм куябыз.

6 Табаны 15-20 минутка 180 градуска кадәр җылытылган духовкага тыгабыз. Әзер булгач, суытып, печенье савытына тутырып куябыз.
Ашларыгыз тәмле булсын!

Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

Бергәләп бизибез!



Истәлекле даталар
2024

ИЮЛЬ

5 июль

Композитор Аллаһияр Гарифулла улы Вәлиуллинның тууына 100 ел (1924–1972)

9 июль

Шагыйрә, журналист Фәйрүзә Әсгать кызы Мөслимованың тууына 70 ел (1954–2021)

12 июль

Гамәли-бизәлеш сәнгате рәссамы Павел Дмитриевич Бойкога 70 яшь (1949)

13 июль

Рәссам, дизайнер Наил Әхкаметдин улы Фәхретдиновка 70 яшь (1954)

19 июль

Рәссам-проектлаучы Юрий Николаевич Галузинга 75 яшь (1949)

20 июль

Җырчы, Татарстан Республикасының халык, Башкортстан АССРның атказанган артисты Рөстәм Гали улы Маликовка 75 яшь (1949)

26 июль

Рәссам-монументалист, Үзбәкстанның халык рәссамы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Озад Гариф улы Хәбибуллинга 75 яшь (1949)

30 июль

Җырчы, педагог, Татарстан АССР, Каракалпакстан АССР һәм Россия Федерациясенең халык артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Зилә Даян кызы Сөнгатуллинага 75 яшь (1949)

АВГУСТ

4 август

Сынчы, Бөек Ватан сугышында катнашкан Әнвәр Кәлимулла улы Бәшировның тууына 100 ел (1924–2000)

13 август

Рәссам-проектлаучы Әнвәр Харис улы Якуповның тууына 70 ел (1954–1998)

18 август

Рәссам Резеда Рәхимулла кызы Ямановага (Ямали) 60 яшь (1964)

19 август

Гамәли-бизәлеш сәнгате рәссамы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Галина Павловна Анютинага 70 яшь (1954)

28 август

Рәссам-проектлаучы, дизайнер, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Александр Петрович Леухинга 75 яшь (1949)

31 август

Рәссам Фәрит Хәмит улы Гаимовка 75 яшь (1949)

31 август

Актёр, Татарстан Республикасының халык артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Искәндәр Илдар улы Хәйруллинга 50 яшь (1974)

СЕНТЯБРЬ

5 сентябрь

Гамәли-бизәлеш сәнгате рәссамы Равил Наил улы Мәхмүтовның тууына 70 ел (1954–1997)

11 сентябрь

Гамәли-бизәлеш сәнгате рәссамы Камил Назыйм улы Акмановка 75 яшь (1949)

13 сентябрь

Композитор, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Шамил Камил улы Шәрифуллинның тууына 75 ел (1949–2007)

16 сентябрь

Шагыйрь, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Шәүкәт Гаделша улы Гаделшага (Сибгатуллин) 75 яшь (1949)

25 сентябрь

Язучы, Татарстан АССРның атказанган мәдәният хезмәткәре Рахмай (Рәхмәтулла) Хисмәтулла улы Хисмәтуллинның тууына 90 ел (1934–2004)

26 сентябрь

Балет артисты, театр белгече, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Владимир Николаевич Горшковка 75 яшь (1949)

Сентябрь

Әлмәт музыка көллияте оештырылуга 60 ел (1964). 1974 елда Ф.З. Яруллин исеме бирелә

https://kitaphane.tatarstan.ru сайтыннан алынды





Кадерле укучыларыбыз!
2024 елның беренче яртыеллыгы өчен «Түгәрәк уен» альманахына республикабызның барлык элемтә бүлекләрендә, яисә «Почта России» сайты аша (https://podpiska.pochta.ru Индекс ПА 183 яисә «Тугарак уен» дип җыярга) онлайн да язылырга мөмкин.

Индексыбыз – ПА 183
Өч айга язылу бәясе – 294 сум 07 тиен
Ярты елга язылу бәясе – 588 сум 14 тиен

БЕРГӘ БУЛЫЙК, ДУСЛАР!